**ҮЗЕБЕЗНЕКЕ ҖИТӘРМЕ?**

**Авыл хуҗалыгы яңа шартларда эшләргә өйрәнә**

> 5

**БАТЫРЛЫК МӘГЪНӘСЕ**

**Бүген Казанда герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә көрәш турниры башлана**

> 16

**ФЛЮРА СӘЛӘЙМАНОВА:**

**«Гомерем кадердә узды»**

> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 37 (28810) | Җомга | 18 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

mchsmedia.ru / архивтан

# ЯЗГЫ ТАШУ

## СУ ТАВЫШЫ: КЕМГӘ – ШАТЛЫК, КЕМГӘ – МӘШӘКАТЬ

**Быел кар күп яуды. Республика халкы шуңа язны шикләнебрәк көтә, су басулар булыр, дип куркучылар бар. КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институтының метеорология кафедрасы профессоры Юрий Переведенцев, март ае беткәнче Атлантика циклоннары өстенлек итсә, язның беренче ае җылы булачак, кар тиз эриячәк, ди. Ул бу хәлләр кайбер урыннарда су басуга китерергә мөмкин дип фаразлый. Халык синоптигы Әмир Шәрәфиев исә, кар күп булса да, су басмас, дип тынычландыра.**

> 6

**Ишетми калмагыз**

## Күбрәк түләячәкләр

Якын арада минималь хезмәт хакын, бюджет тармагы хезмәткәрләренең акчасын, яшәү минимумын, шулай ук барлык социаль түләү, пенсия күләмен арттырырга җыеналар. Россия төбәкләренә социаль-икътисади ярдәм күрсәтү буенча киңәшмәдә ил Президенты Владимир Путин шул хакта хәбәр итте.

«Бәяләр кешеләрнең керемен дә йогынты ясаганын аңлыйм. Шуңа күрә якын арада пособие, пенсия, барлык социаль түләүләрне арттыру буенча карар кабул итәчәкбез. Минималь хезмәт хакы һәм яшәү минимумы күләмен дә, бюджет өлкәсендәгеләрнең дә акчасын арттырачакбыз», – диде дәүләт җитәкчесе.

Президент ассызыклаганча, мондый киеренке шартларда да фәкыйрьлекне киметү өчен чаралар күрергә кирәк. Ул Хөкүмәт вәкилләренә кыска вакыт эчендә эшен югалткан кешеләргә ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәләлеген анализларга кушты. Президент билгеләп үткәнчә, мондый чараларны арттырырга кирәк.

Теманың дәвамы – 2 нче биттә>

## *Акча югалмас*

Билгеле булганча, Халыкара Олимпия комитеты тәкъдиме буенча Россиядә кайбер дөньякүләм турнирларны үткәрүне тыйдылар. Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко әйтүенчә, тотылмый калган акча ил эчендәге спорт үсешенә бүлеп биреләчәк. «Чемпионнар лигасы финалы, волейбол буенча дөнья чемпионаты, Казандагы Махсус олимпиада, хоккей буенча беренчелек, шахмат олимпиадасы һәм башка ярышлар үткәрелмәү сәбәпле, бюджет акчасы сарыф ителми калды. Безнең исәпләүләр буенча, бу – якынча 8 млрд сум. Әлеге акча безнең халык мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләрне хәл итүгә, аерым алганда, Россия төбәкләрендә спорт объектлары төзү һәм ил эчендә чаралар үткәрүгә тотылачак», – диде Дмитрий Чернышенко.

## Парклар саны арта

Быел Татарстанның 49 җирлегендә парк, сквер һәм яр буйларын төзекләндерергә ниятлиләр. Барлыгы 67 объект төзелеше планлаштырыла. Шуларның 11е әр-яңа парк һәм сквер булачак. Бу эшләр өчен федераль һәм төбәк бюджетыннан 2,66 млрд сум күләмдә акча тотылачак.

Узган ел «Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр» Бөтенроссия конкурсында җиңеп чыккан Биләр, Кукмара, Әгерҗе, Баулы, Чистай районнарындагы җәмәгать урыннарын төзекләндерү эшләре дә быел башланачак. Казанда исә 7 парк һәм сквер төзекләндерелер дип көтелә.



**Районнарда ни хәлләр?**

### Арча

Яңа Кишет авылындагы гаражда эретеп ябыштыру эшләрен алып барганда янгын чыга. Бинаны тиз арада төтен баса. Яңа кайткан 30 млн сумлык тракторны шунда керткән булалар. «Мин бу вакытта Иске Кишеттә паркта үземә беркетелгән агрегатларны көйли идем, – ди Зөлфәт Галиуллин. – Төтенне күргәч, шунда ашыктык». Зөлфәтнең куәтле тракторда эшләү тәҗрибәсе бар. Әмма гаражда берни күрерлек булмый. «Башта без ул тракторны өстерәтеп алып чыкмакчы булдык. Барып чыкмады. Шуннан капшап кабинага мендек, чыгу юлын кычкырып, куллар белән ишарәләп күрсәтеп тордылар». Узган шимбәдә район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Ренат Гатиятов батыр егеткә Рәхмәт хаты тапшырды. Ширкәт җитәкчесе аны акчалата премия белән бүләкләде. («Арча-информ»)

### Азнакай

19 мартта Азнакайда ир-атлар арасында бишенче тапкыр республикакүләм Корьән бәйгесе үткәреләчәк. Әлеге ярыш Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан уздырыла. Конкурсны Нәзарәт, көньяк-көнчыгыш казыяте, Азнакай мөхтәсибәте, Азнакай районы хакимияте һәм Шакировлар гаиләсе оештыра. Башка еллардан аермалы буларак, быелгы бәйгедә катнашучылар өч номинациядә көч сынашачак: Корьәннең соңгы ике җүзен яттан белү, Корьәннең соңгы җиде җүзен яттан белү, Корьәнне тулысынча яттан белү. («Татар-информ»)

### Саба

Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы белгечләре кошлар өчен 170 оя элде. «Мондый эшләр кошларның санын һәм төрлелеген саклап калу, шулай ук урманнардагы корткычларны юк итү максатыннан башкарыла», – дип аңлатты урман хуҗалыгының урманны саклау һәм яклау буенча инженеры Зоя Мултанова. Берничә кагыйдәне исәпкә алырга кирәк, ди белгечләр. «Ояны тавышсыз урындагы биеклеге 4 метрдан һәм аннан да югарырак булган агач кәүсәсенә эләргә киңәш ителә. Гадәттә, аны көнчыгыш яки көньяккөнчыгышка таба каратып урнаштыралар. Ояның агачның күләгәле түбәсендә урнашуы бик мөһим, әмма аның алгы ягында ерткычларга ояга керергә булыша торган ботаклар калмаска тиеш», – ди алар. («Саба таңнары»)

### Актаныш

Актанышның «Әнәк» агрофирмасы быелгы язгы чәчүне «Агросигнал» программасы урнаштырылган техникалар белән башкарып чыгачак. «Безнең басуларны үлчисе, машина-тракторларның кайсы басуга барганын, каян кайтканын, күпме чәчү чәчкәнен тикшереп-барлап торасы юк хәзер. Цифрлаштыру технологиясе буенча тракторлардагы датчиклар офистагы белгечләргә бу хакта хәбәр итеп торачак. Бу бик күп чыгымнарны киметергә булышачак», – ди агрофирма директоры Фарис Фәтхиев. («Актаныш-информ»)

tatarstan.ru

### ВЛАДИМИР ПУТИН – РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВКА:

# «МОННАН МӨҺИМРӘК ТАГЫН НӘРСӘ БАР?»

**Президент көндәлеге**

**Эшчеләрне сакларга, төзелешкә ярдәм кирәк. Дәүләт башлыгы Владимир Путинның ил төбәкләренә социаль-икътисади ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча киңәшмәсендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шул сорауларны күтәрде. Ул әлеге утырышта Дәүләт Советының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм шәһәр тирәлеге буенча комиссиясе рәисе буларак та чыгыш ясады.**

**Төзелеш.** Татарстан Президенты сүзләренчә, Хөкүмәт хәер-фатихасы белән комиссия үз эшен дәвам иттерәчәк. Бигрәк тә кәгазь-килешү эшен киметергә кирәклегенә басым ясалды. Дәүләт контрактлары буенча берничә карар кабул ителүен әйтте.

– Коммерциячел торак төзелешен кредитлаштыру мәсьәләсенә дә игътибар итәргә кирәк. Алданган яңа өлешчеләр барлыкка килмәсен, – диде Татарстан Президенты.

Төзелеш кирәк-яракларына бәя арту да борчый. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, бу җәһәттән элекке бәядән материаллар сатып алуны тәэмин итәргә кирәк. Төзелеш һәм юл эшләрен башкарып чыгу өчен махсус техниканы заманчалаштыру, лизинг буенча беренчел кертемне өлешчә яки тулысынча субсидияләү яхшы булыр иде, дип искәртте Татарстан Президенты.

– Система барлыкка китерүче предприятиеләргә ярдәм итү өчен ташламалы кредит бирү программасын эшләтеп җибәрүне һәм яңа транспорт-логистика схемаларын эшләүне тизләтүне сорыйбыз. Импортны алыштыру өчен проектларны финанслау мәсьәләсен карарга һәм төбәкара кооперация эшен җайга салырга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Безнең заказчылар һәм проектлаучылар санкция исемлегенә кергән җиһаз һәм материалларның аналогларын сайлап алу белән мәшгуль. Төп бурыч – төзелеш эшен киметмәү.

**Торак-коммуналь хуҗалык.** Рөстәм Миңнеханов коммуналь хезмәтләргә вакытында түләмәгән өчен пеня исәпләүне үзгәртүне хәзерге вазгыятьтә мөһим чара дип атады. Әмма төбәкләргә бу юнәлештә башкарылачак эшне контрольдә тотарга кирәк. Тарифларны тоткарлау максатыннан, Татарстан Президенты ресурс белән тәэмин итүче оешмаларга акчалата ярдәм күрсәтергә тәкъдим итте.

**Республикадагы вазгыять.** Татарстандагы хәлләргә килгәндә, Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, вазгыять – Хөкүмәт контролендә. Моның өчен махсус штаб та булдырылган, резерв фонды бар. 19 марттан авыл хуҗалыгы ярминкәләре башланачак. Биредә продукцияне кибет бәясенә караганда 20 процентка арзанракка алып булачак, чөнки юл чыгымын республика бюджеты каплый.

**Мәшгульлек.** Татарстанда иң зур зыян машина төзелеше тармагы предприятиеләренә төшәчәк. Әйтик, КамАЗның җитештерү күләме 40 процентка төшәргә мөмкин, заводның 15 меңгә якын хезмәткәре, комплектлау әйберләре белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итүгә кадәр, эшсез торырга мәҗбүр булачак. «Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен федераль ярдәм сорар идек», – дип мөрәҗәгать итте Рөстәм Миңнеханов.

Владимир Путин исә: «Түләем алганда, икътисад өчен дә, кешеләр өчен дә бик мөһим сорау бу. Торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр мохите – моннан да мөһимрәк нәрсә булырга мөмкин?» – диде. Ул аерым заводка гына түгел, ә төзелеш материалларына бәя күтәрелүенә игътибар итте. Бу элегрәк тә күзәтелә иде, дип искәртте Илбашы. «Моны берничек тә аңлатып булмый», – дип аптырады ул. Владимир Путин төбәк җитәкчеләренә бүгенге вакыйгалардан сабак алып, бәяләрне нигезсез арттыруга юл куймаска, моны күзәтеп торырга кушты.

## *Исем генә түгел, җаваплылык та*

Казан тагын бер исемле булды. Татарстан башкаласы рәсми рәвештә Ислам хезмәттәшлеге оешмасының 2022 елгы Яшьләр башкаласы статусын алды.

Бу көннәрдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Казан мэры Илсур Метшин Мәскәүдә Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров белән берлектә республика башкаласына исем бирү инаугурациясендә катнашты.

Президент әйтүенчә, Казанның әлеге исемгә Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үткән вакытта лаек булуы аерым мәгънәгә ия.

Казан Кремлендә шулай ук әлеге вакыйга уңаеннан чара үтте.

Тантанада катнашкан Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Олег Машковцев әйтүенчә, Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр башкаласы исемен Казанга бирүләре юкка түгел.

– Без һәрвакыт Татарстан һәм Казанны яхшы яктан белгәләп үттек, бирелдә төрле чаралар иң югары дәрәҗәдә оештырыла. Планлаштырыла торган чаралар эчтәлеге һәм иң мөһиме – яшьләрне якынайтырга ярдәм итәр, дип ышанам. Сынатмабыз дип уйлыйм, – диде ул.

Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева сүзләренчә, Казанда әлеге юнәлеш буенча эш алып барыла инде. «Чараларны югары дәрәҗәдә оештырачакбыз, моңа барыгыз да ышана ала», – диде вице-премьер.

# ПОЛИЦИЯГӘ ЯРДӘМ КИРӘК

**ТР Дәүләт Советында**

**Татарстан парламентының утызынчы утырышы көн тәртибендәге шактый мәсьәлә акчага бәйле иде. Моңа әллә ни шаккатасы юк, дөньясы бик көйсезләнеп тора.**

Хәтта эчке эшләр министры Артем Хохорин да акчасызлыктан зарланып алды. Бер уйлаганда, полиция әйбәт эшли. Авыр җинаятьләр саны елдан-ел кими бара. Әмма шул ук вакытта технологик алгарышка бәйле җинаятьләр саны арта. Министр әйтүенчә, бу төр җинаятьләргә каршы көрәш узган ел өстенлекле юнәлеш булган. Әлбәттә, җинаятьчеләрне җавапка тарту буенча без Идел буе федераль округында алдынгы, ил күләмендә икенче урында икән. Әмма әлеге хәл «күңел юаткычлары» була алмый. Соңгы ике айда гына да телефон, интернет аша кеше акчасын урлау очраклары узган елның шушы чоры белән чагыштырганда 30 процентка диярлек арткан. Гражданнарның хисап счетларыннан акча урлаучыларны табу һәм җавапка тартуның кыенлыгы турында һәрчак сөйләп торалар. Бу төр җинаять читтән торып кылына, угрылар арасында хәтта чит илләрдә яшәүчеләр дә бар. Полиция хезмәткәрләре җинаятьчеләрне Татарстаннан читтә дә эзләргә мәҗбүр. Алар, мәсәлән, Россиянең башка төбәкләрендә 1685 җинаять кылуда шикләнелгән 1079 кешене тоткарлаган инде.

Министрны борчыган тагын бер нәрсә – наркотикка бәйле җинаятьләр санының шактый ишле булуы. Наркотик саклау һәм тарату белән шөгыльләнүче төркемнәр оешуы. Бездә узган ел гына да җинаятьчеләрдән тоннага якын наркотик матдә алынган, наркотиклар җитештерүче җиде яшерен лаборатория ябылган. Бу төр җинаятьләрнең дә әлеге дә баягы техник алгарышка бәйле булуын әйтеп китик, интернет аша синтетик наркотик сатучы төркемнәр саны ишәйгән.

Министр дәүләт хакимияте органнарында эшләүчеләр арасында ришвәт алучыларны тоткарлау, ялган аракы җитештерүчеләрне фаш итү турында да саннар китереп сөйләде. Кыскасы, полиция хезмәткәрләренең эше муеннан, алай гына да түгел, баш түбәсеннән ашкан. Чөнки җинаять кылулар ишәйгән бер вакытта бездә полиция хезмәткәрләре саны кими икән. Сәбәбе – хезмәт хакының аз булуы, торак белән тәэмин ителмәү. Узган ел эштән китүчеләр саны 1659га җиткән, аннан алдагы елда бу сан 966 булган. Шунысын да әйтик әле: эштән китүчеләрнең күбесе җинаятьчелеккә каршы көрәштә төп эшне башкаручылар – тикшерүчеләр икән. Мондый хәл бездә генә түгел, бөтен илдә күзәтелә. Мәсәлән, узган ел үзләре теләп эштән киткән тикшерүчеләр саны аннан алдагы ел белән чагыштырганда 34 процентка арткан.

Утырышта парламент, полиция хезмәткәрләренең матди хәлен яхшыртуны сорап, Россия Хөкүмәте башлыгына мөрәҗәгать кабул итте.

Татарстанда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец та депутатлар алдында хисап тотты. Ул телгә алган саннар күңелне шактый сагайта. Бала хокукын яклаучыларга мөрәҗәгатьләр саны тагын да арткан. Бу хакык үтенечен колак салынмый дигән сүз түгел, гаилә, бала тәрбияләүгә бәйле мәсьәләләр арта тора. Алар шактый ук дәрәҗәдә бүгенге җәмгыятьнең

Илдар Мөхәммәтҗанов

моралена дә бәйле. Мәсәлән, Ирина Владимировна әйтүенчә, балалар бакчалары һәм мәктәпләрдә килеп чыккан низгышларга бәйле мөрәҗәгатьләр һаман да ишәя тора икән, балаларда агрессия арта. Бу исә яшүсмерләр арасында җинаять артуга китерә. Бала һәм ата-ана арасындагы мөнәсәбәтләр дә әллә ни мактанырлык түгел. Монда имин булмаган гаиләләрнең дә өлеше зур. Юньләп эшләмәгән, хәмерне дус иткән, хәтта наркотик кулланудан да тайчанмаган ата-ана нинди бала тәрбияләсен инде. Андыйларны ата-ана хокукыннан мәхрүм итәләр үзе, әмма ятимнәр йорты балага барыбер дә тулы тәрбия биреп җиткермәячәк. Ирина Волынец әйтүенчә, бүген имин булмаган гаиләләр саны – 1306.

Балалар йортында тәрбияләнгәннәрне торак белән тәэмин итү дә канәгатьләнерлек түгел. Бүген 600 кеше фатирга чират тора, чират исә кимеми. Чөнки акча җитми. Балалар учреждениеләрендә 700 бала бар. Ә гаиләләргә килсәк, алар зур тизлек белән таркала бара: 1 мең никахка 603 аерылышу туры килә икән.

Бөтен сорауларга тулы җавап бирде Ирина Волынец. Артык зарланмады да. Әмма депутатлар штатта эшләүчеләр саны белән кызыксынгач, бары тик биш штат булуын гына әйтеп, Петербург белән чагыштыру китерде. Анда балалар хокукы буенча вәкаләтле вәкилдә 28 штат икән, ә эш күләмендә артык зур аерма юк. Өстәмә штат алырга да акча кирәк шул, ярый әле бездә җәмгать тәртибендә эшләүчеләр шактый.

Тагын бер чыгыш кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм турында булды. Эш кешеләренең хокукларын яклау буенча вәкил Фәрит Габделганиев сүз башында ук «заман чакырулары»н телгә алмый булдыра алмады. Чөнки кече һәм урта эшмәкәрлекнең Татарстан икътисадында өлеше зур. Бу өлешне санга әйләндерсәк, бүген бездә 160 мең шәхси эшмәкәр һәм 787 мең тирәсе үзмәшгуль бар. Алар арасында сәүдә өлкәсеннән җитештерү тармагына күчүчеләр саны артканнан-арта бара.

Фәрит Габделганиев әйтүенчә, узган ел аңа мөрәҗәгать итүчеләр саны кимегән икән: 2020 елда 17,7 мең булса, узган ел нибары 3,7 мең. Мөрәҗәгатьләрнең күп өлеше юридик ярдәм сорауга һәм муниципаль хакимият органнары белән, йомшак кына әйткәндә, аңлашылмаучылыклар килеп чыгуга кагыла. Бәлки, шуңадыр, Фәрит әфәнде районнарга еш чыга, мәсьәләне урында хәл итәргә тырыша. Узган ел Президент Рөстәм Миңнехановның да эшмәкәрләр белән 17 мәртәбә очрашуын, Фәрит Габделганиев инициативасы белән эшмәкәрләрнең Прокуратура, салым хезмәте, башка ведомство вәкилләре белән 39 мәртәбә очрашып-сөйләшүен дә әйтсәк, эшмәкәрлек җитәкчелекнең һәрвакыт күз уңында дип әйтеп буладыр. Әмма барысы да ал да гөл түгел. Фәрит әфәнде бер кызыклы гына фикер әйтеп куйды: нигәдер район-авыл җирләреннән мөрәҗәгатьләр бик аз икән. Моны районавыл халкының артык тыйнаклыгы белән генә аңлату дөрес булмас. Командировка вакытында мин үзем дә эшмәкәрләр белән очрашып сөйләшми калмыйм. Проблемалары турында сорашкач, алар, гадәттә: «Безгә комачауламасыннар гына иде», – диләр. Ә «югары»га хәбәр итәргә шикләнә алар, бу – тыйнаклык түгел, ә ярдәм урынына зыяны булмасын дип шикләнү.

Җирле хакимиятнең бизнеска басымын, контроль-күзәтү органнарының кирәгеннән артык тырышуын Фәрит әфәнде дә яшермәде. Моны җайга салу – иң актуаль мәсьәләләрнең берсе, диде. Күптән килгән тагын бер «баш авыртуы» – җитештергәнне сату. Фәрит әфәнде әйтүенчә, ярдәм булачак, инде тауар кабул итү урыннарын җитештерүчегә якынайту турында җитди сөйләшү бара икән. Шулай ук салым хезмәте белән эшләүне тагын да гадиләштерергә мөмкиннәр, камераль тикшерүләрне азайту турында да уйланалар. Эш башы – уй инде ул.

Санкцияләр заманында җитештерүне киметмәү, үстерү турында махсус план да эшләнәчәк. Фәрит әфәнде әйтүенчә, мондый эчтәлектәге план әле пандемия башланганда ук төзелгән булган.

Барысын да яхшыга юрарга инде. Утырышта бер закон проекты уйга калдырды әле. Ул Татарстанда алкоголь продукциясен ваклап сатуга кагыла иде. Бүген бездә хәмерне кичке сәгать уннан иртәнге унга хәтле сату тыела. Ә федераль дәрәҗәдә хәмер сату 8 сәгатьтән 23 сәгатькә хәтле рөхсәт ителә. Без кемнән ким дигәндәй, депутатлар хәмер сату вакытын федераль нормадагыча билгеләргә тәкъдим итәләр. Әйтүләренчә, чикләүнең һәр сәгате эчендә бюджетка тиешле акчаның 9 проценты керми кала икән. Икенче төрле әйтсәк, хәмер сату вакытын өч сәгатькә чикләү якынча 560 млн сумнан колак кагабыз дигән сүз икән.

Кайбер депутатлар «аек тормыш» сылтавы белән закон проектына каршы килеп маташкан иде. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чикләү юлы белән мәсьәләне хәл итүне хупламады. Ягъни әчәсе килгән кеше хәмерне теләсә кайчан таба, һич югы үзе ясый башлый. Менә шундый кызык хәлләр, эчүчелеккә каршы да көрәшәбез, аракы акчасы да кирәк. «Кыз да булсын, йөкле дә булсын», ягъни мәсәлән.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

**Миллият**

## *Бердәмлек сыналасы ел*

**Бөтендөнья татар конгрессы әгъзаларын шактый зур эшләр көтә. Быел Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы узачак. Конгресс оешуга да 30 ел булган. Кыскасы, үзебезгә дә, читтә яшәүче татарларга, бигрәк тә аларны әйдәп баручыларга эш җитәрлек.**

Бу көннәрдә Казанда X Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены бара. Җыен программасы Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура утырышы белән башланып китте. Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев сүзләренчә, быел бердәмлек аеруча сынала:

– Соңгы ике ел барыбыз өчен дә авыр булды. Пандемияне җиңмәсәк тә, без аның белән яшәргә өйрәндек. Хәзер исә без тагын бер авырлык – Россиягә каршы күпсанлы санкцияләр белән очраштык. Президент Владимир Путин кабул иткән карарларны хуплыйбыз, шул ук вакытта тынычлык телибез. Җир йөзендә иминлек булсын иде, – диде ул утырышта. – Шура вәкилләренең күпчелеге белән күзгә-күз очрашу форсатыннан файдаланып, шуны әйтәсем килә: татарларны берләштерүче чаралар күбрәк булсын иде. Истәлекле даталарыбыз бар, ярдәм кирәк булса, теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итә аласыз.

Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездына әзерлек эшләре белән конгрессның Башкарма комитет җитәкчесе Данис Шакиров таныштырды. Быел ул 31 июль – 2 августта узачак. Утырышта съездның оештыру эшләре турында сөйләштеләр. Катнашучылар турында да сүз булды. Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә кагылышлы мәсьәлә генә бераз бәхәс тудырды. Әйтик, Татарстанның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, юл мәшәкатен һәм чыгымнарын исәпкә алып, онлайн форматның уңайлыклары турында искәртте. Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров исә бу фикер белән килешмәде. «Игътибар итәсез микән сез: руслар моның кебек мәртәбәле чараларга һәрвакыт чит илләрдән фикердәшләрен чакыра. Авыр чакта ярдәмгә килүче булсын өчен. Милләт мәсьәләсен кайгыртканда кыенлыклар турында уйламаска кирәк», – диде ул.

Мәскәү өлкәсе татар мәдәни-милли мохтарияте җитәкчесе Фәрит Мөхтәсәров исә өлкәләрдә яшәүче татарларга бердәмлек җитеп бетмәве турында әйтте. «Милләттәшләребез белән очрашулар уздыру, активистларны бүләкләү, гомумән, игътибар күрсәтү – безнең өчен үтә мөһим. Берәүгә дә сер түгел: безгә бердәмлек җитеп бетми. Шуның өчен киләчәктә дә аралашып торыйк», – диде ул.

Сүз уңаеннан, утырышта быелгы Федераль Сабан туеның уздырылу урыны һәм вакытын да атадылар. Быел бәйрәм Ульяновск өлкәсендә 18 июньдә узачак. Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе исә 2 июльгә планлаштырылган. Ул Мордовиянең Аксен авылында узачак.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

# *Шешә*

Каты көнкүреш калдыклары турында сүз инде ничә еллар дәвам итә, әмма чүп кимегәне бик сизелми. Алга киткән илләрдә чүп эшкәртеп ни генә ясап бетермиләр! Рәхәтләнеп акча эшлиләр. Чит ил тәҗрибәсен үзебездә дә куллану кирәклеге турында иң югары даирәләрдә сүз бара, әмма сүздән ерак китә алмыйбыз. Чүп арасында пластиктан ясалган шешәләр аерым урын алып тора. Аларны җыеп бару өчен һәр ишегалдында диярлек аерым савытлар да булдырылды, әмма шешәнең әлеге савытлардан соңгы язмышы турында без берни дә белмибез диярлек. Татарстанда пластик шешәләр, пакетлар эшкәртүче 5 предприятие барлыгын әйтәләр үзе, әмма «чүптән акча ясыйбыз» дип горурланучылар гына юк. Эшмәкәрләр бу эшкә нигәдер бик теләп алынмый.

Яшь чаклар искә төшеп китте әле. Совет чорында бөтен сыек әйбер пыяла савытларда сатыла иде һәм банка-шешәләр валюта урынына йөрде. Бөтен җирдә «Стеклотара» кабул итү пунктлары эшләде. Буш шешәләр без – студентлар арасында да популяр иде. Шулай булмыйни, өч-дүрт шешә тапшырып, ашханәдә рәхәтләнеп әбәд ашап чыга идек. Тулай торак бүлмәләрендә буш шешәләр сак астында торды. Чит бүлмәгә бер генә шешә дә бирмәскә тырыштык, аларны югалту шактый ук зур фаҗигагә әйләнә иде. Стипендиядән колак каккан сабакташларга да ярдәм йөзеннән буш шешә бүләк итү матур гадәткә әйләнде.

Ә кабул итү пунктларына шешә тапшыру үзе бер кызыклы традиция, бәйрәм кебек иде. Күз алдыгызга китерегез: шешә тутырылган тишекле сетка тотканнар горур кыяфәт белән Казан урамы буйлап бара. Аннан соң кабул итү пунктына чиратка баса. Кайчак сетка күтәргән студентка тагын берәү ияргән була. Бу үзенә күрә сак хезмәте инде. Ягъни мәсәлән, шешә акчасы тулысы белән тулай торак бүлмәсенә кайтырга тиеш. Тапшырган кеше «общак», ягъни уртак байлыкка кул тыкмасын! Шуның өстенә шешә кабул итүчегә дә контроль кирәк бит. Ул «башы кителгән» дигән сылтау белән синең берничә шешәңне үзенә калдыра, аннан соң барыбер тапшыра. Юкса шешә кабул итүчеләр Казан байларына әйләнмәс иде. Алар турында «бер ел эчендә машина алган» кебек хәбәрләр еш ишетелде.

Хәзер пыяла савытларның абруе кимеде. Хәмердән башка күп ризык, төрле сыеклыклар пластик савытларда сатыла, хәтта сыраны калай банкаларда саталар. Пыяладан тулысынча ваз кичеп булмый, әлбәттә. Мәсәлән, кайнатмалар пыяла банкаларга тутырыла.

Тик менә пластик савытларга «икенче гомер» бирү мәсьәләсе барыбер дә хәл ителә алмый әле. Бәлки, яңадан пыяла шешәләргә кайтыргадыр?!

Шушы көннәрдә Идел буе федераль округының закон чыгару органнары җитәкчеләре Казанга киңәшмәгә җыелды. Белүемчә, көн тәртибендәге иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе каты көнкүреш калдыкларына кагыла һәм шешәләр турында да бер-бер сүз чыкмый калмас. Чөнки көнкүреш калдыклары экологик афәткә китерәчәк дип еш сөйли башладылар. Әйтүләренчә, дөньяның 35 иле пластиктан баш тарткан инде. Ә Франциядә полиэтилен пакетлардан файдаланучыларга, гомумән, төрмә яный икән. Чүп арасында пластик шешәләр – иң яманы, диләр. Алар үзләре таркалсын өчен 100 елдан 500 елга кадәр вакыт кирәк, имеш. Хәер, бу имеш-мимеш түгелдер. Елына бездә, бер кешегә исәпләгәндә, 166 шешә сатыла. Бу – бер кеше елына 5 кило пластик чүп җыя дигән сүз. Бер елдан Россиянең 17 төбәгендәге чүплекләрдә пластикка урын калмаячак, диләр.

Ә пластик чүпне эшкәртүче заводлар Россиядә бик аз, берәүнең дә чүпкә тотынып вакланасы килми.

Елына безнең илдә 24,3 миллиард данә пластик шешә сатылуын әйтсәк, киләчәк турында уйларга да куркыта. Европа бер тапкыр файдаланыла торган пластик әйберләр җитештерүне, гомумән, тыйган, диләр. Ирексездән, кайда безнең пыяла шешәләр, стаканнар, диясе, пыяла шешә кочаклап ятасы килеп китә. Әстәгъфирулла!

Әгәр Идел буе федераль округының законнар чыгару органнары советы утырышында пластик чүпләр, шул исәптән шешәләр язмышын хәл итәрдәй берәр карар кабул ителсә, борчылып язуларым чүп булып калыр һәм моңа бик шатланыр идем.

# АКЧА-МАКЧА, АЛТЫН-МАЛТЫН, ДЕФОЛТ-МЕФОЛТ

pixabay.com

Дөньяның асты өскә килгән кебек тоела башлый икән, ул тетрәнүләрнең нигезендә акча-финанс мәсьәләсе ята. Валюта тотрыклы булса, илләр һәм кешеләр тыныч кына яшиләр. Акчага ышаныч беткәндә, сәүдә сугышлары, икътисад сугышлары башлана.

Бу юлларның авторы әлеге темага 15 елдан артык яза инде. 2006 елда «Акча-макча» дигән язмада: «Туксан икенче елдагыга караганда да куәтлерәк финанс кризисы һәм бөек таркалу көтәргә мөмкин без яшәгән ватанны. Бу исә капитализм потенциалының тагын ничә елга җитүенә генә бәйле», – дип язганмын, мәсәлән. Интернетта эленеп тора ул язма. Кисәтмәкче булганмын инде. 2008 елда исә «Алтын-малтын» дигән язмада: «Без Америка һәм Европа илләре, Кытай һәм Япония, Һиндстан кебек державаларның энергетик чимал базарлары өчен үзара тарткалашулары якынлашкан бер чорда яшибез. Бу исә – Өченче Бөтендөнья сугышының дәһшәтле адымнары инде кызулана бара дигән сүз. Аның беренче канонадаларын инде Әфганстан һәм Гыйракта ишетергә була. Чиратта – Иран һәм Сүрия. Бу исә конфликтка Кытай һәм Һиндстанның да тартып кертелүе дигән сүз», – дип кисәткәнмен үземчә. Игътибар итегез: ул чакта әле Сүрия иттурагыч хәрәкәткә килмәгән һәм тыныч кына яшәп яткан ул илдә вәхшәт башланыр дип беркем дә уйламый иде. Хәзер карагыз: Көнбатышның бөтен державалары (Россияне дә кертеп) ул илдә үз гаскәрләрен тота, беркем дә чыгарырга уйламый. Нидер көтәләр…

Хәзер бүгенге вазгыятькә карыйк. Россиянең алтын-валюта резервлары Көнбатышта бикләнде. Монда 300 миллиард доллардан артык акча турында сүз бара. Олигархларның чит ил банкларында туңдырылган акчасы 400 миллиард доллар тирәсе дип әйтәләр. Яхталар, затлы күчемсез милек бу суммага керми дип беләм. Финансчылар Россиянең дефолты турында сүз алып баралар. Дефолт булса да, булмаса да, безнең хәл начараячак, монысына шикләнмик. Мин үзем киләчәктә Америка һәм Кытай кебек гигантларның да дефолтын көтәм. Искә төшерик: дефолт ул – әҗәтләрне түли алмау дигән сүз. Хәзерге көндә Россия банклары сумнарны долларга алыштырмый бит. «Кара базар»да гына валюта алып була. Анда исә доллар бәясе 200–300 сумга җитә. Тагын бер нәрсәне искәртик: «кара базар»дан валюта алу җинаять дип санала, моның өчен 7 елга кадәр утыртырга мөмкиннәр. Кайбер Россия банклары азәрбайҗан манаты, чин юане, казах тәңкәсе, төрек лирасы, һинд рупиясендә дә кертемнәр ача башлаганнар икән. Син банкка сумнар белән киләсең, кертемне син теләгән валютада ачалар ягъни. Кайсы валюта ышанычлырак дип саныйсың, шул валютага сыенасың. Россиягә карата чикләүләр кертмәгән теләсә кайсы ил валютасын сайлый аласың. Беләсезме, валюталарның берсе дә ышанычлы түгел, хәтта доллар да. «Акчаны сумда сакласаң ышанычлырак, сум күче астыннан аны беркем дә эзләмәячәк», – дип анекдот сөйләү сумның бөтенләй абруе калмавын дәлилли. Әмма дә ләкин сум өеме астына тыгардай ышанычлы бер валюта да юк бүген. Доллар дисезме? Вакытлыча ярап тора инде ул яравын. Әмма газета хәбәрчесе менә мондый хәбәр алды кичә: «Wall Street Journal яза: Согуд Гарәбстаны Кытай белән нефтьне юаньга сату турында сөйләшүләр алып бара». Доллар өстендә бик зур яшен яшьни дигән сүз бу. Согуд нефтенең дүрттән өч өлешен исә Кытай сатып ала. «Кара алтын» бәясен төшерү өчен, АКШ Президенты Байден Согуд Корольлегенә һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә әллә ничә тапкыр шалтыратты, телефонны алмадылар, дип тә әйтәләр. Дөрес, Дәүләт департаменты моны фейк дип кире кага, әмма гарәпләр нефть чыгаруны арттырырга бик тырышмыйлар – монысы хак. Төрекләр Россия белән – сумда, һиндлылар рупийда сәүдә итәргә риза. АКШ лидерлыгы югалып, доллар системасы җимерелеп килә. Сум күче астына доллар яшерергә теләсәгез, яшерегез, әмма бик озак срокка түгел.

Берничә көн элек кенә Владимир Путин, алтын коелма сатып алганда, НДС түләүдән азат итә торган законны имзалады. Моңа кадәр 20 процентка кыйммәткәрәк алырга туры килә иде алтынны, НДС өстәлә иде. Әмма барыбер 24 февральгә кадәр алтын коелма сатып алсаң, ота идең. Алтынның доллардагы бәясе дә, долларның сумга курсы да бик үсте чөнки. Әмма бүген сумга алтын коелма алып булмый дип беләм. Банклар аны долларга гына саталар. Ни өчен сумның абруен төшерәләр, аны кимсетәләр? Сәясәтнең нигезендә шул ята: чит илләр белән сәүдә итү өчен доллар кирәк, ә россияле халыкның итек кунычында һәм матрас астында йөзләгән миллиард доллар бар. Менә шуларны әйләнешкә кертергә телиләр. Ә бит башкача эшләп була иде. Берничә ел элек үк сумга алтын стандарт кертсәң, ягъни алтынга берсүзсез алыштырыла ала торган итсәң, берәү дә пыяла банкада доллар пачкасы сакламас иде. Инфляциягә бирешми торган һәм курсы түбәнәйми торган валютага ия булыр идек. Алтын да тик ятмас, сәүдә әйләнешенә кереп, икътисадны күтәрергә булышыр иде. Бик зур потенциалга ия ул алтын акча. 1917 елгы революциядән һәм бөлдергеч Гражданнар сугышыннан соң илдә ачлык-ялангачлык хөкем сөргәндә, Ленинның башы эшләп, әйләнешкә червонец – алтын белән тәэмин ителгән акча кертә. Бизнес шунда ук хәрәкәткә килә, икътисад шунда ук күтәрелә башлый, кибетләр товар белән тула. Бүгенге вазгыятьтә дә червонец Россия икътисадын күтәрергә булыша алыр иде, әмма аны кертмәячәкләр, чөнки хәзерге глобаль капитализм кагыйдәләре аны кабул итә алмый. Капитализмны җирләгәннән соң, әйләнешкә алтын-көмеш акчалар кирәчәк, бу шиксез. Әмма аңа кадәр Сүриядә тупланган гаскәрләрнең бик каты бәрелешкә керәсе бар әле. Алтын-көмеш акчалар беркайчан да кыйммәтләрен югалтмыйлар алар. Туксанынчы елларда чегәннәр өйдән-өйгә йөреп, әбиләр чәчкә таккан талир тәңкәләрне сорап йөрделәр бит әле. Аларның чын кыйммәтен беләләр иде чөнки. Югары совет чиновниклары да ришвәтне Бохара әмире суккан алтын тәңкәләрдә ала торган булганнар дип әйтәләр. Бик зур һәм кызыклы тема бу, әмма мәйдан төгәлләнгән икән инде. Аннан соң Швейк афоризмнары да безгә күп сөйләшмәскә куша. «Тиләләр йортында һәркем парламенттагы кебек башына ни килсә, шуны сөйли ала», – дип әйтә дә ул әйтүен. Без тиләләр йортында түгел. Парламентта түгел дә түгел инде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

# ИРКӘЛӘНЕР ЧАК ТҮГЕЛ

## АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ САНКЦИЯЛӘРНЕ НИЧЕК КАРШЫ АЛА?

**Татарстан үзен ит, сөт һәм йомырка белән – 100, шикәр һәм көнбагыш мае белән 300 процентка тәэмин итә, әмма авыл хуҗалыгында чит илләргә бәйлелек тә зур. Шуңа күрә ике арадагы чик республика аграрийлары өчен зур проблемалар китереп чыгарды. Валюта курсының өскә үрмәләве техника, токымлы терлек, ашламалар, чәчүлек орлыклары, корткычларга каршы көрәш чаралары, мал-туар дарулары кыйммәтләнүгә китерде. Чит илдән авыл хуҗалыгы техникасын кайтару белән дә проблемалар бар. Ә алда – аграрийлар зур өметләр баглап көткән кыр эшләре сезоны. Мондый шартларда авыл хезмәтчәннәре нинди кәеф белән эшли һәм нинди ярдәмгә өметләнә? «ВТ» хәбәрчесе аларның хәлен белеште.**

«ВТ» архивыннан

### «Мондый хәлне күргән юк иде»

Үзгәрешләр авыл хуҗалыгының һәр тармагына кагылачак. Бердән, бәяләр артса, икенчедән, сәяси вазгыять шартларында техника, җиһазлар һәм запас частьларны кайтарып булмавы бар. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сүзләре буенча, республиканың техника паркында ашлык җыя торган комбайннарның – 29, терлек азыгы җыя торганнарының – 26, үзйөрешле чапкычларның – 70 (!), шикәр чөгендере җыя торган комбайннарның 75 (!) проценты читтән кайтарыла. Техниканы кыр эшләренә әзерләр өчен 4,5 млрд сум акча тотыла, шул исәптән 2,7 миллиарды – башка илләрдән кертелгән техника өчен. Соңгы берничә атна эчендә генә дә чит ил техникасына запас частьларга бәя 3 тапкыр арткан. Дөрес, аларны үзебезнекеләргә алыштыру буенча эш алып барыла. Тик һәр көн алтынга тиң вакытта моңа өлгерергә дә кирәк бит.

Актаныш районының «Әнәк» агрофирмасы директоры Фарис Фәтхиев чабатасын алдан әзерләп куя торганнардан. Шуңа күрә ул: «Күңел бераз тынычрак», – ди.

– Орлыкларга акчаны алдан түләп куйган идек. Аларның тәэмин итүчеләргә (поставщик) кайтканын хәбәр иттеләр. Шуңа күрә монда проблема булыр дип уйламыйм. Ә менә чит илдән кайтарыла торган гербицидлар, техника белән авырлыклар бар, – ди җитәкче. – Кайбер җитештерүчеләр, акча алдан түләнгән булуга карамастан, бәяне арттыра. Ярар, аларны аңлашыла инде. Үзебезнең ил эчендә бәяләр 40–45 процентка күтәрелде бит. Менә шунысына шаккатабыз. «Ростсельмаш» 20 млн сумлык комбайнныңның бәясен 55 млн сумга кадәр арттырды. Ә хуҗалыклар ел саен техникасын алыштыра. Килешү төзелгән, акчасы алдан бераз түләнгән, бер айда техниканы кайтарып бетерергә тиеш иде. Моны эшләмәделәр. Хәзер менә яңа хәбәрләре килеп төшә... Үз илебездә дә шулай булгач инде... Чит илнеке кайтмаса, бар өмет шуларда иде бит.

Аның сүзләренчә, шикәргә бәйле күренеш авыл хуҗалыгы тармагына да хас. Ягъни аграрийлар, ясалма ыгы-зыгы тудырып, бәяләр күтәрелүгә китерә. Фарис Фәтхиев кредит процентларының артуыннан да зарланды. Ташламалы кредит процентлары (3,8%) шул ук калса да, коммерцияле кредитлар 21–24 процентка күтәрелде.

– Коммерцияле кредитны 11 процент белән алган идек, икенче көнне үк 21,5 процентка күтәреп куйдылар. Гомумән алганда, күп хуҗалыклар, агрофирмалар быел кышны болай да авырлык белән чыкты. Беренчедән, терлек азыгы җитми. Икенчедән, булган ашлыкның үзкыйммәте бик югары. Сатып, табыш ала торган түгел. Әле ярый мин ашламаларны ташып бетереп куйган идем, күпчелек эшләрен көнендә хәл итеп бара торган хуҗалыклар, белмим, нәрсә эшләп бетәр? Авыл хуҗалыгына бервакытта да җиңел булганы юк анысы, тик быел нык авыр булачак... Безнең әле мондый хәлне күргән юк иде. Елы уңышлы килгән очракта да, табышка чыгып булырмы, беркем әйтә алмый, – диде ул.

### Игенчелек

Татарстанда бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар белән тәэмин ителеш 115 процентны тәшкил итә. Ә менә шикәр чөгендере, көнбагыш һәм кукуруз белән кыенлыклар бар. Кукуруз белән – 92, шикәр чөгендере белән – 77, көнбагыш белән 75 процент кына тәэмин ителгән. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы китергән мәгълүматларга караганда, 2019 елда җирнең нибары 0,6 процентына гына үз илебездә җитештерелгән шикәр чөгендере орлыгы чәчелгән.

«Агросила» холдингының матбугат үзәге «ВТ» хәбәрчесенә биргән мәгълүматларга караганда, шикәр чөгендере орлыгы буенча берничә дә проблема юк.

– Холдингның бер төр орлык белән дә проблемасы юк, – диде безгә белгеч. – Барысы да алдан хәл ителгән. Бүгенгә аларны алып кайту, логистика мәсьәләләре генә калып бара. Соңгы партия булып шикәр чөгендере орлыгы кайтачак. Килешү буенча, анысы 10 апрельдә бездә булырга тиеш. Бүген орлыкларның күпчелеген Германиядә, Франциядә, Бельгиядә, Даниядә җитештерәләр. Без соңгы ике илдән алдык. Һәр җитештерүче килешүдә алдан күрсәтелгән күләмнәрне раслады. Чәчү сезоны 15 апрельдән башлана, шуңа күрә авырлыклар булмас, планлаштырган эшләрне башкарып өлгерербез дип уйлыйм.

### Йомырканың бәясе дә йомры

Терлекчелек, игенчелек кенә түгел, санкцияләрнең авырлыгын кошчылык тармагы да үз җилкәсендә шактый татыячак. Чөнки Росстат мәгълүматлары буенча, халыкка җитәрлек йомырка тулысынча үзебездә җитештерелсә дә, токымлы тавыклар, күркә, каз һәм үрдәк чыгару өчен йомыркаларны кош фабрикалары чит илдән кайтарта. Бу күрсәткеч 20 процентны тәшкил итә. Шуңа күрә инкубатордан чыккан чебешләр сезоны шулай ук югары бәяләре белән шаккатырырга мөмкин. Россия авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев җиткергән мәгълүматлар буенча, берничә ай эчендә инкубация йомыркалары ике тапкыр диярлек арткан: 16–17 сумнан 30 сумга менгән.

Тукай районының «Мусабай» хуҗалыгы – кошчылык буенча уңышлы эшләп килүче оешма. Алар тавык, үрдәк сата, кош ите эшкәртә. Фермер хуҗалыгы башлыгы Айгөл Ханова әйтүенчә, алар чималны һәм кош ризыгын Россиядән кайтарта. Быелга инкубация йомыркаларының да хәстәрен алдан күргәннәр. Ә менә киләсе елга ни булыр – билгесез, ди ул.

– Россиядә бигрәк тә бройлер инкубация йомыркалары һәм токымлы кошлар җитми. Миңа калса, чебешләрне сатып алучылар кимер. Үзкыйммәте бик нык артты: азык, электр энергиясе, ягулык. Ә халыкның кереме артмады. Әгәр моңа кадәр хуҗалык өчен 50 бройлер чебеше алсалар, быел 20 белән генә канәгатьләнәчәкләр. Узган ел тавыкны 180 сумнан саткан булсак, быел ул инде 260 сум тора.

Җитештерүчеләрнең бәяләре кредит процентлары арту хисабына да күтәрелә. Чөнки моңа кадәр 12% белән түләнгән бурычны хәзер 25% белән кайтарырга туры килә. Фермер фикеренчә, хәзер кредитлар алу һәм терлек азыгына субсидияләр бирү бик актуаль булыр иде.

– Ташламалы кредитлар бирү бар, ләкин безнең республика өчен ул бик аз. Барлык эшмәкәрләр өчен 200 млн сум. Шуңа күрә бу программага бик аз гына фермер эләгә. Лимит күләмен арттырсалар, яхшы булыр иде. Узган ел терлек азыгына субсидия бирелде, ләкин ул сөтчелек тармагына гына эләкте, – диде Айгөл Ханова.

### «Халык үзен үзе кайгыртырга тиеш»

Россиядә шулай ук орлыклык бәрәңге белән тәэмин ителеш тә начар. Яшелчәчелек белән шөгыльләнүче фермерлар әйтүенчә, быел орлыкларның вакытында килеп җитмәү куркынычы бар. Республиканың кайбер эре хуҗалыклары бәрәңгенең Голландия, Германия сортлары белән эшли. Шулай ук бәрәңге җыя торган комбайн бәяләре дә котырып арткан.

Татарстанның абруйлы фермеры Минталип Минеханов ярминкә, балалар бакчаларын һәм мәктәпләрне, ашханәләрне, булеп бирү үзәкләрен бәрәңге һәм башка яшелчәләр белән тәэмин итә. Аның фикеренчә дә, илдәге үзгәрешләрнең авыл хуҗалыгына йогынтысы зур. Ягулыкның 84 процентын кулланучылар да – аграрийлар. Бигеле булганча, бәяләр монда да тик тормый. Болардан кала, корткычларга каршы көрәш чараларына, әлеге дә баягы техникага, запас частьларга хаклар күтәрелде. Ләкин авырлыкларга карамастан, алга карап эшләячәкбез, ди фермер.

– Авыл хуҗалыгы министрлыгы ярдәм кулы сузарга әзер булуын әйтте үзе. Аларга өметләнәбез, тик үзебезгә дә тырышырга туры киләчәк. Кайда нәрсәне алыштырып була, шуларны карарга кирәк. Ләкин аналогларның да бәяләре артты. Шулай да артка чигенергә хакыбыз юк. Елның уңышлы килүен телик. Шул ук вакытта су сиптерүне дә һичшиксез җайларга кирәк, – ди ул.

Хуҗалык орлыклык бәрәңгене Россиянекен сатып ала. Ә менә калган яшелчә орлыклары чит илдән кайтарыла. Аларын инде кайтарып өлгергән булганнар.

– Орлыклык бәрәңгене моңа кадәр читтән кайтарган хуҗалыкларга юрганына карап аякларын сузарга туры килер, – ди ул. – Хәлләре авыр, кредит өстендә яши торган хуҗалыклар булган техникалары белән эшли торыр яки тотылганын сатып алу ягын карар дип уйлыйм. Россия техникасы да, ватылып-җимерелеп, эшне тоткарлый бит әле. Сүз дә юк, чит илнеке ышанычлырак, әмма хәзер алар янына якын килерлек түгел. Тагын шунысы мөһим: бу шартларда халык үзен үзе кайгыртырга тиеш. Буш яткан бакчаларга бәрәңге утыртырга, җирдә эшләргә иренмәгез, дип киңәш итәм. Иркәләнеп ятар чак түгел.

Зөһрә САДЫЙКОВА

# ЯЗГЫ ТАШУ

## СУ ТАВЫШЫ: КЕМГӘ – ШАТЛЫК, КЕМГӘ – МӘШӘКАТЬ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

**«Язны 52 ел куркып көтәм»**

Кайбыч районының Борындык авылында яшәүче Роза Саттарованың йортына бер елны да су кермичә калмый. Кар аз яуган елларны да идән астына керә икән.

– Язны 52 ел куркып көтәм инде. Йортыбыз үзәнлерәк җирдә салынган. Азаплансак азапланабыз, әмма башка җиргә күчәргә уйламадык та. Гомерем буе февраль ахырында бөтен кирәк-яракны барлап җыя башлыйм. Шулай өйрәнелгән. Ташу зур була, дисәләр дә, быел булмый, дисәләр дә, барыбер хәстәрен күрәм, – ди ул.

Роза апа ике авыру баласы белән яши. Алар олы яшьтә булсалар да, әниләренең ярдәме кирәк үзләренә. Язгы ташу аның өчен икеләтә мәшәкатьле. Йорттагы әйберләрне, мал-туар, кош-кортларны да күчерергә кирәк. Балаларын да янынннан җибәрә алмый. Үзләре дә әниләреннән башка туганнарына да барып тормый икән.

– Ничә еллар шулай яшибез инде. Безнең гараж өсте бар. Бар әйберне шунда ташып куябыз. Баздагы кирәк-яракны да өскә күтәрәбез. Өйдәге җиһазлар болай идәннән метр ярымга күтәртелеп куелган инде безнең. Ташу булыр дип торсак та, быелгы һава торышы белән су кермәс дип уйлыйм. Кар күп яуса да, ул җиргә сеңеп барды. Салкын көннәр торганда да кояш үз эшен эшләде. Карны эретте. Булса да, сүз юк – ташу күрмәгән кешеләр түгел лә инде без.

Яшел Үзән районының Татар Танае авылын ел да су баса. Авыл янәшәсеннән узучы Гөбенә, Ышналы елгаларының күтәрелми калганы юк икән.

– Узган ел авылга су кермәсен өчен дамба ясап куйдылар. Шуңа да быел тынычрак торабыз. Авылга су кермәс дип өметләнәбез. Кар күп яуса да, ул куркыныч түгел, басу, урманнардагы сулар төшеп, елга ташырга бик мөмкин. Әмма су кермәс дип, кул кушырып утырмыйбыз. Өйрәнелгән инде. Бөтен кирәк-яракны җыештырып куйдык, – ди шушы авылда яшәүче Рабига Баһавиева.

Тукай районының Теләнче Тамак җирлеге башлыгы Рамил Шәрипҗанов белән дә сөйләштек. Ул су басмас дигән фикердә. «Бездә елга-ярлар биек. Кар да әкренләп басылды. Шуңа да су басар дип курыкмыйбыз», – ди ул.

Арчаның 12 авылына су төшәргә мөмкин икән. Районның гражданнарны саклау идарәсе җитәкчесе Гөлнар Шәрипова әйтүенчә, бу авылларга су керсә, 232 хуҗалык су астында калырга мөмкин икән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Социаль объектларга, икътисад, тормыш иминлеген тәэмин итүче объектлар, үләт базлары, күперләр, гидротехник корылмаларга су басу куркынычы янамый, – ди ул. – Районда язгы ташуны бәла-казаларсыз уздырып җибәрү өчен барлык чаралар да күрелә. Су үткәрүче канаулар, су торбалары, күперләр кардан һәм чүп-чардан вакытында чистартылып тора. Район халкыннан да әзер торулары сорала. Әмма кешеләр бик аңлап бетерми әле. Әзерләнергә ашыкмыйлар. Кайдандыр ярдәм килгәнен көтәләр. Күпләп кар эрегәндә күңелсез нәтиҗәләрне китерергә мөмкин. Үз йортлары белән яшәүчеләргә кар суы ага торган канаулар казырга, йорт яннарын чистартырга кирәк.

**«Ташу булса, суга тиенер идек»**

Буа районына яз иртә килә. Аларда ташу да башкаларга караганда бер атна алдан башлана. Халыкның кәефе ничек, ташуга әзерләнәләрме икән дип, Түбән Наратбаш авылында яшәүче Нурдания Низамиевага шалтыраттык. Алар ташудан курыкмый, аны дүрт күз белән көтә.

– Авылны су басса, сөенер идек әле, – дип башлады сүзен Нурдания апа. – Без бер ел буе сусыз утырабыз. Кулны юарга да суыбыз юк. Түбән Наратбаш һәм Бикмураз авылларына су килми. Күлебез дә кипте. Ичмаса, ул булса да, суга тиенер идек. Кичә кич Ульяннан концерт куеп кайтып кердек. Кулны юарга дип кранны ачкан булам. Бер тамчы су юк! Бар өмет язгы ташуда. Зөя ташып, безнең күлебезгә су керсә иде, дип телибез.

Район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Илдус Гыйззәтов сүзләренә караганда, ташуга әзерлек башланган инде. Карны читкә чыгаралар, су юлларын, юллардагы торбаларны чистарталар икән.

– Элек Кыят елгасы күтәрелеп, авылларны су баса иде. Быел яңа асфальт юл салынды, су баса торган урыннар күтәртелде. Шуңа да күперне су басса да, авылларга кермәячәк. Бәбки авылын су басу куркынычы бар. Кирәк-яраклар әзерләнде. Халык та кисәтелде, – ди ул.

Форсаттан файдаланып, Түбән Наратбаш авылындагы сусызлык мәсьәләсен дә күтәрдек. «Без бу хакта беләбез, җир астында су кипте. Әлеге авылларга су кертеләчәк. Финанс мөмкинлекләр җитсә, быел ук кертергә җыенабыз», – диде җитәкче.

Узган ел редакциягә, су басудан зарланып, Мамадыш районының Күкчишмә авылыннан шалтыратканнар иде. Ул чакта авылга кайтучылар, кер алмыйбыз, күпер юк, дигәннәр иде. Быел алар ташуга әзерме икән? Усали авыл җирлеге башлыгы Альмир Зыятдинов хәлне аңлатып бирде.

– Күкчишмә авылын халык Ташлык дип йөртә. Берсут елгасы күтәрелгәч, күпергә су керә. Югары Әрнәш авылы буасын да алып китә ул ташу. Әмма Күкчишмәгә өч яктан кереп була. Анда яшәүчеләрне беркайчан да ташламыйбыз. Мин аларга әйтеп тә куйдым – кемгә нәрсә кирәк, алып килеп бирәчәкмен. Без ташуга әзер. Күпергә керү – бер хәл, йортларга зыян салмасын иде, – ди ул.

**Казанны да басачак**

Башкалада язгы ташу иртәрәк, 20 мартта ук күзәтелергә мөмкин. Казан шәһәр башкарма комитетының гражданнарны яклау идарәсе җитәкчесе Фердинант Тимурханов шулай ди.

– Су басуны киметү максатында, шәһәр эченнән кыш дәвамында 900 мең тонна кар чыгарылды. «Шәһәр күперләре» оешмасы Киндерле, Вертлевка, Коры Елга һәм Нокса елгаларындагы күпер асларын чистартты. Төрле урыннарда төзелгән 34 җәяүлеләр җир асты кичүләре тирәләре кардан арындырылды, – диде ул. – Казанда су баса калса, 9395 кешене йортларыннан вакытлыча күчерергә туры киләчәк. Моның өчен 20 пункт әзерләнеп куелды инде. Кинәт җылытып җибәрсә, су басу ихтималы зур.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

> Республикада су басу куркынычы булган 220 торак пункт бар. Быел Азнакай районының – 18, Биектауның – 16, Лениногорскиның – 15, Арчаның – 12, Апас, Кайбыч, Яшел Үзән районнарының 10 авылына су керергә мөмкин. Су басу куркынычы янаган районнар арасында Мамадыш, Минзәлә, Тукай, Пит)рәч, Балтач, Буа, Мөслим, Сарман, Теләче, Яңа Чишмә, Әлки, Әлмәт, Баулы, Кама Тамагы, Нурлат, Әгерҗе, Ютазы, Әтнә, Кукмара, Чирмешән, Лаеш, Түбән Кама районнары да бар.
> Татарстанда язгы ташу вакытында 17 мең кеше һәм 2,5 мең техника җәлеп ителәчәк.

**ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ СУ БАСУ ОЧРАГЫНДА ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕН ИСКӘРТӘ:**

- иң беренче газ һәм электрны өзегез;
- су акрын күтәрелгән очракта кыйммәтле әйберләрне югары катларга яки чормага менгерегез, хайваннарны чыгарыгыз;
- күршеләрегезне кисәтегез, балаларга, өлкәннәргә, инвалидларга куркыныч янаган урыннан китәргә ярдәм итегез. Югары катка, чорма, түбәгә менегез. Гражданлык хәлләре штабы хәбәрләрен тыңлагыз һәм алар әйткәннәрне төгәл үтәгез;
- эвакуациягә әзер булыгыз. Тиз арада куркынычсыз урынга чыгарга тырышыгыз;
- үзегез белән документлар, акча, кыйммәтле әйберләр, җылы киемнәр, берничә көнгә җитәрлек азык-төлек, су, шәхси гигиена әйберләре, медицина аптечкасы алыгыз;
- су эчендә калсагыз, җылы киемнәрне, аяк киемен салыгыз һәм якын-тирәдә су өстендә йөзүче әйбергә ябышырга тырышып, коткару хезмәте килгәнен көтегез;
- сулы юлдан машина белән йөрүдән тыелыгыз, агым белән алып китәргә мөмкин. Әгәр су баскан урында калып, машинагыз ватылса, ярдәм чакырыгыз;
- иң мөһиме – тынычлык саклагыз һәм куркуга бирелмәгез!

> Татарстанда 12 мартка кар катламы 54 сантиметрны тәшкил иткән, бу соңгы еллардагы күрсәткечтән 20 сантиметрга биегрәк. Казанда кар катламы 67 сантиметрга җиткән иде. Карда су запасы уртача күрсәткечтән 1,5 мәртәбә күбрәк. Җирдә туң катламы – 46 сантиметр.

25 март сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә Садыйкова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

# ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

## Ятим баланы гаиләгә алган өчен күпме түләнә?

Ятим баланы гаиләгә алган өчен түләүләр арткан дип ишеттем. Аның тәртибе турында аңлатып үтсәгез иде. Ул кемнәргә тиеш, нинди документлар кирәк, бөтен гаиләләргә дә бириләме икән?

**Сәлимә ХӘКИМОВА. Казан**

**Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге матбугат хезмәте җавап бирә:**
– Сүз ятим бала алган гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган акча турында бара. Ул баланы уллыкка алучыга яки опекунга рәсмиләштерелергә мөмкин.

Ел башында уллыкка алынган һәр балага 18886,32 сум бирелә иде. Әгәр дә инде балага 8 яшь тулган яки ул инвалид бала булса, шулай ук гаилә бер ата-анадан булган берничә баланы уллыкка алса, бер тапкыр 144306 сум түләнә иде. Март аеннан индексацияне исәпкә алып, бу түләүләр 20472,77 сум һәм 156428,66 сумга җиткерелде.

Әлеге пособиегә гаризаны тиешле документлар белән Пенсия фондының яшәү урыны буенча бүлегенә илтергә кирәк. Бу гаризаны уллыкка бирү турында суд карары чыккач яки опека органының опекага алу турында карары кабул ителгәч, яки инде баланы гаиләгә алу турында килешү төзелгәч язарга кирәк. Гариза язу вакыты чикле булуы һәм аның 6 ай каралуы турында да искәртик.

Пенсия фондына гаризаны почта аша да юлларга мөмкин. Бу очракта тиешле документларның күчермәләре нотариус тарафыннан расланырга тиеш. Әлеге гаризага уллыкка алынган баланың туу турындагы таныклыгы, судның уллыкка бирелү турындагы карары яки опекага бирү турындагы карары күчермәләре беркетелә. Пособие билгеләнү турындагы карар гариза кабул ителгәннән соң 10 эш көне дәвамында чыгарыла. Пенсия фондына билгеле оешмалардан мәгълүматлар вакытында килеп ирешмәгән очракларда ул 20 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин. Пособие гариза бирүчегә 5 эш көне аралыгында күчерелә.

Пенсия фондының республика бүлеге мәгълүмат үзәге телефоны: **8 800 6-000-000**.

## Акчасын алалар, чүбен түкмиләр

Авылда чүп чыгарган өчен акчасын алалар, чүбен җыймыйлар. Аны кая куярга белгән юк. Халык нишләргә тиеш?

**Исем-фамилиям редакция өчен генә. Буа районы Алших авылы**

**Алших авыл җирлеге башлыгы Александр Андреев аңлатмасы:**
– Кыш көне чүп чыгаруда чыннан да кыенлыклар булды. Әмма бу чүп җыючы машина авылга килмәде дигән сүз түгел. Ул даими йөрде, ләкин кайбер атналарда үзәк урамнардан гына узды. Безнең Алших – өч урамлы авыл. Бөтен юллар да төзек, кайсына асфальт түшәлгән, кайсына таш җәелгән. Юлларны чистартып торсак та, юл тар ачылган, батабыз дип, машина бөтенесенә дә керә алмады. Үзегез беләсез, кыш бик карлы килде, бөтен урамнарны да киң итеп ачарга мөмкинлек булмады. Хат авторы читтәге урамда яши булса кирәк. Аларга үзәк урамдагы чүп чыгара торган урын күп дигәндә 500 метр ераклыкта инде. Мартта чүпне бөтен урамнардан да җыйдылар, башка андый проблема булмаячак.

## Безгә нишләргә?

Миңа – 85, тормыш иптәшемә – 82 яшь. Икәү генә яшибез. Андыйларга капиталь ремонт өчен түләтмиләр дип ишеттек. Белешкән идек, департаментка да бардык, түләргә, ди. Татарстанда, имеш, шулай каралган. Түләргә тиешме икән без?

**Мөхәммәтзакир КАМАЛОВ.**
***Әлмәт шәһәре***

**Ләйсән ХАЛИКОВА, финанс белгече:**
– Әлеге компенсациягә эшләмәүче, ялгыз яшәүче торак хуҗасы өмет итә ала. Аларның яше җитмеш яки өлкәнрәк булу шарт. Ташлама ир белән хатыннан торган гаиләгә дә бирелә ала. Бу очракта гаилә башлыгының – 60, хатынының 55 яшьтән узуы шарт.

**Рәзил БИЛДАНОВ, юрист:**
– Бу сорауның нечкәлекләре бик күп. Кем белән торуы, кем пропискада булуы да әһәмияткә ия. Әгәр дә өйдә аннан кала башкалар да теркәлгән, моңа өстәп яшь тә булсалар, ташлама каралмаган.

Компенсацияне исәпләүдә дә игътибарлы булырга кирәк. Монда фатирның ничә бүлмәле булуы, квадрат метры исәпкә алына. Төбәк өчен капиталь ремонтка каралган норматив һәм тарифлар бар. Ул шулар буенча исәпләнә.

Бу компенсация ташлама буларак бармый. Ягъни квитанциядә сумма ким булып килмәячәк. Торак милекчеләре (яки аларның вәкилләре) квитанцияне тулы күләмдә түлиләр, ә аннан соң теркәлү урыны буенча халыкны социаль яклау органына мөрәҗәгать итәләр, анда капиталь ремонт өчен чыгымнарны компенсацияләүгә гариза язалар.

### Укучы сүзе

Газетабызның исеме дә горур: «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»! Интернетта язылган яңалыкларны укуга караганда, газета битләрендәге яңалыкларны уку ул мичтә пешкән кайнар коймак кебек. Газетаның һәр санын көтеп алам! Менә хәзер дә сезне бик игътибар белән укыйм! Уңышлар һәм илләребезгә тынычлык телим!

Әлфия НӘЗИРОВА

**«АВЫЛ ТОТКАЛАРЫ ҖЫЕЛА»**
«Сельсовет» хуҗасы күптән инде буш җирләрне шәһәр кешеләренә «под дачу» сатып ята. Күпме тели һәм ничек тели, шулай сата. Кабинетына авыл кешесе сорау белән килсә, исәнләшми дә, телефоныннан ике сәгать «узенеке»ләр белән сөйләшә. Аннан соң гына сорау бирергә тилмереп утырган кешене күрә. Менә шундый хуҗалар да бар. Алар белән ничек авыл хуҗалыгын торгызып булсын?! Минемчә, авылга югары уку йортын тәмамлаган яшь, чын мәгънәсендә белемле, җир яратучы белгечне башлык итеп куярга кирәк. Хәзергеләренең уенда – җир сатып, кесә калынайту. Мин нәкъ менә үзебезнең авыл турында яздым.

Карина КӘРИМОВА

***

Авылдан шәһәргә барып, арзан бәядән продукция сатарга кушалар. Ә нишләп шәһәрдән авылга килеп арзан бәягә әйбер сатарга кушмыйлар? Шәһәргә гел арзан кирәк, ә авылга кыйбаты да ярыймы?

Хәмдия ШӘРИПОВА

**«БЕР ҖЫЛЫ СҮЗ ҖИТӘ»**
Шулай инде, бер дәреслек тә юк. Авыл җирендә 30 ел эшләп пенсиягә чыккан хисапчыларга 25 процент өстәмә булмады. Колхозда чөгендер, бәрәңге эшкәртүдә, ферма агарту һәм башка эшләрдә бухгалтерия эшләде. Дөресен әйткәндә, «разнорабочий» булдык. Хезмәт хакын да тиешенчә түләмәделәр, «риза булмасаң, эштән кит» дип, авызны ябалар иде. Ә колхозны түйганчы талаган рәисләргә өстәмә түләү булды. Бер дәреслек тә юк!

Әминә АСЫЛГӘРӘЕВА. Тукай районы

**ЯМАН ШЕШ БЕЛӘН КӨРӘШҮЧЕ НӘФИСӘ САБИРҖАНОВА БЕЛӘН ӘҢГӘМӘГӘ КАЙТАВАЗ**
Әңгәмәдән күренгәнчә, сез – көчле хатын, нык булыгыз, көрәшегез! Мин бу авыру белән ирем авырый башлагач очраштым, сырхаулар белән аралашудан, бу авыру турында укып, шуны аңладым: рухи халәт, көрәшү көче, терелүгә ышану бик мөһим. Сәламәтлек сезгә!

Дамирә ГӘРӘЕВА

***

Куркып калмагыз. Апама 56 яшендә операция ясадылар, алты сәгать барды, апам операциядән чыккач, Җир йөзендә бер кеше калмаса да, мин яшим, диде. 23 сеанс нурланыш алды, күп кенә химия терапия кичерде һәм терелде! 83 яшендә бакыйлыкка күчте.

Әлфия ЗАРИПОВА

Гөлинә ГЫЙМАДОВА әзерләде

## 21 март | Дүшәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Народная игрушка 6+
00.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25, 12.15 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ЯНЫЧАР» (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 Док. расследование М. Леонтьева «Большая игра». Фильм 1-й 18+
01.00, 03.05 Информационный канал 16+
03.00 Новости

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ГОДУНОВ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
02.05 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
03.30 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 14.50 Новости
06.05, 19.15, 21.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.25 Смешанные единоборства. One FC. Адриано Мораэш против Деметриуса Джонсона. Трансляция из Сингапура 16+
10.30, 04.30 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
13.55, 14.55 «БОЛЬШОЙ БОСС» 16+
16.05 «Громко». Прямой эфир
16.55 Хоккей. КХЛ. 1/2 финала конференции «Восток». «Салават Юлаев» (Уфа) – «Трактор» (Челябинск). Прямая трансляция
19.25 Хоккей. КХЛ. 1/2 финала конференции «Запад». Прямая трансляция
22.30 Тотальный футбол 12+
23.00 «ГОНКА» 16+
01.20 Бокс. Bare Knuckle FC. Лучшее 16+
02.00 «Человек из футбола» 12+
02.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+
03.55 «Наши иностранцы» 12+
04.25 Новости 0+
05.20 «Громко» 12+

### НТВ

05.35 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Максим Щеголев, Алексей Барабаш, Вадим Андреев. «ПОРТ» (S) 16+
23.40 «ПЁС» (S) 16+
03.35 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2022» 16+
06.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Без адреса» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «РАДУГА В НЕБЕ» 16+
19.00 «АКВАМАРИН» 16+
23.05 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2». 51-я и 52-я серии 16+
01.00 «Эффект Матроны» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «НА БЕЗЫМЯННОЙ ВЫСОТЕ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15, 18.30 «Специальный репортаж» 16+
09.35, 01.35 «ПЕРВЫЙ ТРОЛЛЕЙБУС» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости. 16+
14.05, 03.50 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
18.50 «Война миров». Док. сериал. «Подземные мстители красного Крыма» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным 16+
20.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Операция «Турнир». Большая игра». Премьера! 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
23.40 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ»-3 16+
03.00 «Особый отдел. Контрразведка». Док. фильм 12+
03.40 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+

## 22 март | Сишәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». «Вадим Кешнер. Артист. Учитель. Человек» 12+
00.40 «Каравай». Уникальный промысел 6+
01.05 «Реквизиты былой суеты» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ЯНЫЧАР» (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 Документальное расследование Михаила Леонтьева «Большая игра». Фильм 2-й 18+
01.00 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ГОДУНОВ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
02.05 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
03.30 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 14.50 Новости
06.05, 21.45, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.25 «БОЛЬШОЙ БОСС» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
13.55, 14.55 «МАКСИМАЛЬНЫЙ СРОК» 16+
16.00 «ПОСЛЕДНИЙ САМУРАЙ» 16+
19.00 Хоккей. КХЛ. 1/2 финала конференции «Запад». «Спартак» (Москва) – СКА (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
22.00 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Маккаби» (Израиль) – «Милан» (Италия). Прямая трансляция
00.40 «Есть тема!» 12+
01.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Лучшее 16+
02.00 «Голевая неделя» 0+
02.25 «Оседлай свою мечту». Док. фильм 12+
03.55 «Правила игры» 12+
04.25 Новости 0+
04.30 «Мэнни». Док. фильм 16+

### НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «ПОРТ» (S) 16+
23.40 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
03.25 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Верный пёс» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «РЕФЕРЕНТ» 16+
19.00 «ОТПУСК В СОСНОВОМ ЛЕСУ» 16+
23.10 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2». 53-я и 54-я серии 16+
01.05 «Эффект Матроны» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 01.35 «ТРАКТИР НА ПЯТНИЦКОЙ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Война миров». Док. сериал. «Киллеры британской короны» 16+
19.40 «Легенды армии». Константин Вершинин. Премьера! 12+
20.25 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
23.40 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ»-3 16+
03.05 «Вторая мировая. Русское сопротивление». Док. фильм 12+
03.50 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+

# ЙОЛДЫЗНАМӘ 21–27 МАРТ

**КУЧКАР (21.03 – 20.04)**

Эшегездә үзгәрешләр көтелә. Вәкаләтләрегез артачак, гомумән, карьерагыз яңа борылыш алачак. Аннан аермалы буларак, шәхси тормышта яңалыклар көтелми.

**ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)**

Һөнәри өлкәдә үзегезне күрсәтүдән курыкмагыз – йолдызлар сезнең яклы. Күп вакытта иҗади фикерләвегез ярдәм итәчәк. Ләкин артыгын эшләп ташламагыз, ял турында онытмагыз. Якыннарыгыз, дусларыгыз белән очрашып, ялларны саф һавада уздырсагыз яхшы.

**ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)**

Бу атнада сезгә ял итәргә һәм көч тупларга киңәш ителә. Апрель башында тормышыгызның яңа этабына аяк басачаксыз. Агымга каршы йөзәргә яратсагыз да, бу атнада бераз тынычланып торыгыз. Шәхси тормышыгызда да тотрыклылык сакларга тырышыгыз.

**КЫСЛА (22.06 – 22.07)**

Яңа эш тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Ә сез баш тартырга ашыкмагыз – яхшылап уйларга кирәк. Үзегезне күрсәтер өчен менә дигән мөмкинлекне кулдан ычкындыра күрмәгез. Ялыгызны яраткан кешегез белән, гади генә тоелган нәрсәләрдән дә тәм табып үткәрегез.

**АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)**

Бу атнада юлыгызда шактый гына каршылыклар очрар, ләкин сез барыбер уйлаган эшегезне ахырына кадәр җиткерегез. Ялгызларга бу атнада бәхет елмаячак: көтмәгәндә, уйламаганда насыйбыгызны табып куярсыз.

**КЫЗ (24.08 – 22.09)**

Табигатегез буенча сак кеше булсагыз да, соңгы берничә атнада сезгә үзгәрергә туры киләчәк. Нинди дә булса карар кабул иткәндә, йөрәгегезне тыңлагыз – алданмассыз. Ә ялларыгызны үзегез теләгәнчә уздырыгыз – сез моңа лаек.

**ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)**

Бу атнада беразга гына булса да туктап, үз гамәлләрегезгә бәя бирер өчен мөмкинлек булачак. Кайчандыр очына чыга алмаган мәсьәләгә ачыклык кертерсез. Ә шәхси тормышка килгәндә, сезне күңелле сюрпризлар көтә.

**ЧАЯН (24.10 – 22.11)**

Атна вакыйгаларга бай булачак, шәхси тормышыгызда сезне кардиналь үзгәрешләр көтә. Һәм алар яхшыга булачак. Көтмәгәндә хезмәт хакыгыз артып куярга мөмкин – барысы да сезнең тырышлыктан торачак.

**УКЧЫ (23.11 – 21.12)**

Гыйшык утларында янучы Укчыларның хисләре сыналачак. Сезгә хәзер шәхси ирек мөһимдер, ләкин мөнәсәбәтләрдә ике якның да теләкләрен исәпкә алырга кирәк шул…

**КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)**

Хезмәттәшләрегез белән бәхәскә кермәгез, югыйсә эшегездә кыенлыклар чыгачак. Бу киңәшкә колак салсагыз, атнаның икенче яртысында күңелле яңалыклар көтәчәк. Күптән онытылган идеяләрегезне тормышка ашырып карагыз әле, рухи яктан да, матди яктан да канәгать булып куюыгыз бар.

**СУКОЯР (21.01 – 19.02)**

Кисәк килеп туган хәлләргә яраклашырга туры киләчәк. Сәфәргә чыгудан курыкмагыз – юл сезне кызыклы кешеләр белән таныштырачак.

**БАЛЫК (20.02 – 20.03)**

Финанс мәсьәләсендә сак булыгыз, акчаны уңга-сулга тарата торган чак түгел. Ләкин кыенлыклар озакка бармаячак. Ял көннәрен туганнарыгызга багышлагыз. Күптәнге танышыгыз кунакка чакырса, баш тартмагыз.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлектә казанышларга ирешүләре һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе башлыгы **Идиатуллин** Артур Рево улы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары **Олонова** Юлия Николаевна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Минханов** Рамил Гаяз улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Нигез» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы **Мирзамөхәммәтов** Идгар Тимергали улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасында «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәте төбәк башкарма комитеты җитәкчесе **Фазылов** Ринат Рафаэль улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың урман хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасының «Алабуга урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесенең Морт участок урманчылыгы участок урманчысы **Шәйхетдинов** Мәҗит Заһри улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

# ГАДЖЕТ БУЫНГА БӘРӘ

pixabay.com

**Замана чире. Табиблар буын авыруларын әнә шулай дип атый. Бүген Җир шарында яшәүчеләрнең 30 проценты шушы авырулардан интегә. Соңгы арада буын авырулары яшәрә бара, дип чаң суга белгечләр. Аз хәрәкәтләнү, дөрес тукланмау нәтиҗәсе бу. Буын авырулары тагын ни сәбәпле пәйда була? Алардан тулысынча котылып буламы?**

**Медицина фәннәре кандидаты, терапевт, ревматолог Регина АХУНОВА буын авырулары турында иң еш ишетергә туры килгән фикерләргә ачыклык кертте.**

**1 Буын авырту – өлкәннәр чире.** Өлкәннәр генә түгел, яшьләр дә, хәтта балалар да буын авыртудан интегә ала. Аның сәбәпләре күп төрле булырга мөмкин. Шуңа күрә буыннар борчый башласа, иң элек табиб-ревматологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ник дигәндә, башлангыч чорда ук кичекмәстән дәвалау таләп итәлгән буын авырулары бар. Вакытында чарасын күрмәсәң, алар инвалидлыкка китерергә мөмкин. Ревматологка күренергә мөмкинлек булмаса, терапевт яки педиатрга барырга кирәк.

**2 Буыннар һава торышы үзгәрү арасында да борчый ала.** Кайбер кешеләр, дөрестән дә, һава торышы үзгәргән көннәрдә буыннар сызлаудан зарлана. Бу атмосфера басымы түбәнәюгә бәйле. Вак кан тамырлары белән нерв күзәнәкләре моңа әнә шул рәвешле җавап кайтара.

**3 Буыннар тоз утырганга күрә сызлый.** Буын авыртуның сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Буыннар тоз утырганга сызлый дигән очрак «подагра» диагнозы куелган кешеләргә кагыла. Сидек кислотасы тозлары буынга җыелып авырттыра башлый.

**4 Буын авырулары нәселдән күчә.** Нәселдән нәселгә күчә торган буын авырулары бар. Әйтик, ата-анасы, әби-бабасы ревматоид артрит белән авырган кешеләргә дә шундый куркыныч яный.

**5 Буын авыртудан тилмергән кешегә физик күнегүләр тыела.** Бу очракта да иң элек буыннарның ни сәбәпле авыртуын ачыкларга кирәк. Хәрәкәт, физик күнегүләр, йөзү буыннарга файдага гына. Әмма буын авыруы баш калкыткан чорда физик күнегү, эшне киметергә кирәк. Әгәр инде авырткан урынның төсе, буынның формасы үзгәрсә, шикләнергә җирлек бар.

**6 Буыннар авыртканда баллы һәм ысланган ризыклар ашарга ярамый.** Бар нәрсәне дә чама белән генә ашарга кирәк. Буыннары авырткан, бигрәк тә «подагра» диагнозы куелган кешеләр ит, балык шулпасы, кыздырылган, томалап пешерелгән, ысланган ризыклардан, соя, фасоль, борчак кебек кузаклылардан тыелырга тиеш. Бу очракта яшелчә ашына, куян, тавык ите, сөт һәм сөт ризыкларына өстенлек бирергә кирәк. Буын авыруының иң көчәйгән чорында ит һәм балыктан бөтенләй баш тарту хәерле.

**7 Гаджетлар буын авырулары китереп чыгара.** Соңгы арада мондый чирләрнең артуына гаджетлар белән бергә, аз хәрәкәтләнүебез дә гаепле. Артык авырлык та буыннарга өстәмә басым ясый. Ул бигрәк тә оча, бот, тез буыннарын зарарлый. Артык авырлык артериаль гипертония, шикәр чиренә дә сәбәпче була ала.

**8 Буын авыруларын ахыргача дәвалап бетереп булмый.** Буын авыруларын никадәр иртәрәк дәвалый башласаң, шулкадәр яхшырак. Диагноз вакытында куелса, чир азуны, буыннарның формасы үзгәрү, хәрәкәт чикләнүне булдырмый калырга мөмкин. Замана медицинасы авыруны туктатып кына калмыйча, аны тулысынча дәваларга да мөмкинлек бирә. Шуңа күрә чирне үзлегеңнән генә дәваларга ярамый. Буын авыруларын кисәтү өчен, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, дөрес тукланырга, күп хәрәкәтләнергә кирәк.

### БУЫН АВЫРУЛАРЫН КИСӘТҮ ӨЧЕН БЕРНИЧӘ КИҢӘШ

- Аягүрә озак тору, аякларның берсен икенчесе өстенә куеп утыру зыянлы. Озак вакыт иелеп эшләү дә зарарлы.
- Биек үкчәле аяк киеменнән баш тарту, биек аркалы утыргычка утыру да – буыннарга бик зур ярдәм.
- Кайберәүләр, буыннарны язабыз дип, баскычтан җәяү менә, төшә. Бу шулай ук зыянлы.
- Утырып эшләгәндә аякларны селкетеп алу яки пластик шешәгә су тутырып, шуны тәгәрәтү дә файдалы.
- «Остеоартроз» диагнозы куелганда, махсус җайланма – ортезлар кулланырга, өченче таяну ноктасы булдырырга кирәк. Әйтик, уң як буын авыртса, сул кул белән таякка таяну шарт. Болай эшләү буыннарга көч килүне киметә.

## *Чәч тәрбия сорый*

Яз көне чәчләр тәрбиягә аеруча мохтаҗ. Коры чәчне йомырка белән юарга ярамый. Чөнки аксым баш тиресен бик нык тарттыра. Ә менә кефир чәчләргә, киресенчә, файдалы. Әмма аны мунчага кергәнче сыларга киңәш ителә. Эсседә ачы сөт бактерияләре һәлак була. Кефирлы масканы өй шартларында башыгызны артык җылытмыйча ясыйсыз икән, ул бөтен файдалы үзлекләрен саклаячак. Моның өчен майсыз кефирны җылытып, чәчкә сылыйбыз да башка полиэтилен пакет киеп, сөлге урыйбыз. Ярты сәгатьтән чәчне шампунь белән юабыз. Чәч коелудан тилмерүчеләр исә түбәндәге масканы ясап карый ала. Ярты стакан кефирны җылытып, бер чәй кашыгы бал салып болгатабыз. Чәчкә сылап, шулай ук полиэтилен киеп куябыз да сөлге урыйбыз. Бер сәгатьтән юабыз.

Кавыктан интегүчеләр дә масканы кул астындагы әйберләрдән дә ясый ала. Андый чакта суган, сарымсак һәм лимон ярдәмгә киләчәк. Беренче маска: уылган бер баш суганга 2 аш кашыгы аракы һәм 1 аш кашыгы кастор мае кушып болгатырга кирәк. Икенче төр масканы ясау өчен, уылган бер тырнак сарымсакка 100 г җылытылган әрекмән мае кушасы. Өченче маска 4 аш кашыгы зәйтүн маена 1 аш кашыгы лимон согы кушып ясала. Бу маскаларны башка сылаганнан соң, полиэтилен пакет киеп, бер сәгатьтән соң гына юып төшерергә кирәк.

### Үзем сынадым

## Тамак авыртудан котылдым

Тамак авыртудан котылуның бик шәп ысулын таптым. Бер чәй кашыгы тозга бераз гына лимон суты, бер чәй кашыгы бал, ярты чәй кашыгы горчица һәм 100 мл җылы су салып, яхшылап болгатырга һәм шуның белән көнгә берничә тапкыр тамакны чайкатырга кирәк.

Әлфия САБИРОВА. Биектау

### Исеңдә тот!

## ЙОКЫСЫЗЛЫКТАН КОТКАРА

Булмә гөлләре буенча белгеч – Британиядә яшәүче Ричард Чешир йокысызлыктан коткаручы гадәти булмаган ысулны атаган. Белгеч фикеренчә, йокы бүлмәсендә күпьеллык үсемлек – валериана үсеп утырса, кешенең йокысы яхшыра. Валериананың киптерелгән тамырыннан тынычландыручы дарулар ясауларын ишеткәнегез бардыр. Белгеч сүзләренчә, бу үсемлек бүлмәне дә бизи, аның татлы исе йокыга талырга булышачак. «Үзенең кечкенә алсу һәм ак төстәге чәчәкләре белән валериана сезнең йокы бүлмәгездә матур булып утырачак, – ди Чешир. – Аны йөзәр еллар элек йокы белән проблемалар булганда, шул исәптән йокысызлыктан җәфаланганда да кулланганнар. Валериана тамыры исен сулау да йоклап китәргә булыша һәм йокының сыйфатын яхшырта».

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Үзем сынадым

## ЙОМЫРКА КАБЫГЫ – АШЛАМА

Берничә ел элек йомырка кабыгы җиләк бирүче куаклар өчен бик файдалы ашлама дип ишеткән идем. Инде ничә ел чи йомырка кабыгын ташлаганым юк, җыеп барам. Аларны юам, эчендәге элпәсен алам һәм кип-терел тартмаларга тутырам. Көз көне әлеге кабыкны уклау ярдәмендә изәм һәм яфрак койган куакларның төпләренә чокыр ясап салып чыгам һәм өстен туфрак белән күмәм. Кышкы дым әлеге файдалы ашламаны тамырга илтеп җиткерә. Ә уңыш елдан-ел арта, мин бик канәгать!

Асия ГӘРӘЕВА. Арча

Исеңдә тот!



## ЛИНОЛЕУМ КУБАРАБЫЗ

Келәйгә утыртылган линолеумны ансат кына кубаруның бер ысулы бар. Аның өчен юкарак сөлгене һәм кайнар үтүк кирәк булачак. Линолеумның нык ябышкан урынына сөлгене куеп, аның өстеннән кайнар үтүк белән йөртеп алыгыз. Келәе җылынгач, ул бик ансат кына тулысынча кубарып алыныр.

Белеп тор!

## *Тегермәннең файдасы*

**Борычваклый торган тегермәнне башка максатта да кулланырга була икән.**

1 Әлеге тегермән белән чипсы изәргә мөмкин. Изелгән чипсыны кәтлитләр әвәләү, ашка салу, салат бизәү өчен кулланырга була.

2 Мондый тегермәндә вакланган кипкән гөмбәне ашка яки итле рулетлар ясаганда салыгыз, бик тәмле булачак.

3 Кипкән банан һәм җиләкләрне әлеге тегермән аша чыгарып, туңдырма һәм десертларны бизәү өчен кулланырга мөмкин.

# САРЫККА ДА ЯРАТУ КИРӘК

**Күп еллар сарык асраучы Зөлфия Дәүлиева, Корбан өчен малларны аерым игътибар биреп ашатыр вакыт җитте, ди.**

Гөлнара Зиннәтуллина

**Ничек сайларга?**

– Корбанга олы сарыкларны да, 3–4 айлык бәрәннәрне дә хәзердән тиешенчә тәрбияли башларга кирәк. Аларны башкаларыннан аерым ашатсаң да яхшы. Гомумән, корбанга гына түгел, җәйге сугым өчен дә сарыкларны хәзердән әзерли башлыйбыз. Олырак сарыкны симертү өчен 45–50, яшь малны симертергә 90–100 көн чамасы кирәк. Симертү өчен бәләкәйдән аппетиты яхшы булган, тиз үскән малларны сайлыйм. Хайванның тышкы кыяфәтеннән үсү-үсмәвен чамаларга мөмкин. Сәламәт, яхшы үсәсе малның иңбашы җилкәсенә караганда киң, гәүдәсе озын һәм төз, ә янбашлары түгәрәкләнеп торган була. Асылынып төшкән хәлсез иңбашы, тырпаеп торган калак сөяге, хәлсез аяклар – малның күпме генә ашатсаң да мантымаячагы турында сөйли. Тагын бер мөһим нәрсә – бәрәннең аягы нык булсын. Андыйлар тиз үсә һәм авырлыкны да тиз җыя.

**Ничек ашатырга?**

– Ашатуга килгәндә, мин көненә өч тапкыр ашатам. Иртәнге ашауга бөртеклеләрдән арпа, бодай яки солы бирәм. Бераз тоз салынган су һәм печән бирәм. Төшке ашка көрпә белән чөгендер, су, ә кичкесенә ипи белән коры печән бирәм һәм су салам. Булса, рационга силос та кертсәң, бик яхшы. Бераз тоз салган су сарык малының гел алдында булсын. Ә бер эчүендә бераз сода салсаң да яхшы, ул маемлаудан саклый. Чөнки икмәк белән тукланганда сарыкның ашказаны аны кайчак эшкәртеп бетермәскә мөмкин.

Малны ашатырга гына түгел, яратырга да кирәк. Аларга гел матур сүзләр белән генә дәшәм, безнең абзарда малга кычкырган һәм сүгенгән кеше юк. Тагын көн саен малларны һавага алып чыгып йөртсәң дә бик әйбәт. Мин, гадәттә, төшке ашларын абзардан чыгарып ашатырга тырышам. Гомумән, ябылуда яткан малга караганда иркендә йөргән сарыкның ите тәмлерәк була.

Бакчачыга

## УҢЫШЫ МУЛ БУЛА

**Тәҗрибәле бакчачылар помидорлар эре, уңышы күп булсын өчен берничә киңәшне истә тотарга куша.**

✓ **ТӨБЕН ӨЮ**

Беренче тапкыр помидорның төбен һава тамырлары барлыкка килгәннән соң өяргә кирәк. Икенче тапкыр аның сабаклары төсе бераз зәңгәрләнеп киткән төсле булганнан соң өяргә киңәш ителә. Соңрак помидор төбенә торф, коелган яфраклар өстәп өйгәндә уңыш тагын да яхшырак булачак.

✓ **ЯФРАКЛАРЫН ӨЗҮ**

Помидорның яфракларын даими өзү турында да онытырга ярамый. Яфрак янындагы ботакка әверелеп килүче үсенте, сабак астындагы яфракларны өзәргә киңәш ителә. Бу чәчәк атуны һәм помидорлар төшүне тизләтә.

✓ **ТУКЛАНДЫРУ**

Помидор даими тукландыруга мохтаҗ. Чәчәк атуга помидор «куагы»на коры көл сибеп чыгарга кирәк. 3 литрлы суга 100 г чүпрә һәм шикәр комы салган катнашманы ачытып, аны 10 л су белән болгатып, һәр төпкә бер стакан сибеп чыгарга киңәш ителә.

Аш булсын!

## Ипи пешерү ысулы

**Кошман авылында яшәүче Гөлсирә Яруллина ипине шикәр комы, сөт һәм йомырка салмый гына пешерә икән. Рецепты бик гади, ә ипи бик тәмле була.**

Бер литр суга бераз чүпрә, тоз он салып кичтән болгатып калдырырга. Иртә белән шуңа он кушып болгатып, кабартырга куярга һәм аннары формаларга яки табага салып, җылытылган мичкә озатырга. Ипи 1 сәгать тә 15–20 минут чамасы пешә.

Остаханә

## ЯШЕЛ УЕНЧЫК

**Урамда яз кояшы елмая. Хәзер балалар белән бергәләп яшел уенчык ясар өчен менә дигән вакыт.**

Яшел уенчык ясау өчен буш йомырка кабыгы, йомырка савыты, теләсә нинди яшелчә яки бөртекле культура орлыгы, маркер, су һәм мамык кирәк булачак. Йомырканың очланып торган башын сак кына ватып эчен агызабыз. Маркер яисә фломастер белән күз, борын һәм авыз ясыйбыз. Йомырканы савытына урнаштырып, эченә мамык салабыз. Өстенә орлык салып, су сибәбез дә тәрәзә төбенә куябыз. Орлыкны бик каты тутырмаска кирәк, чөнки ул бөртеп, йомырка кабыгы ярылып китәргә мөмкин. Кипкән саен су сибеп торырга кирәк. Ә яшел үсентеләр 7–10 көннән соң пәйда булачак. Яшел уенчыклар балагызның да, сезнең дә кәефегезне күтәреп торыр. Кирәк дип санасагыз, уенчыкның «чәч»ен кисәргә, тасмалар белән бизәргә дә мөмкин.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

# ҖАНГА-ТӘНГӘ ЯЛ – МУНЧАДА

**Ислам – чисталык дине, диләр. Өс-башны пөхтә тоту, юыну, таһаратле булу – һәр кеше өчен тиешле гамәлләрдән. Шунысына да игътибар итми мөмкин түгел: юыну урыны саналган мунча хәзер кәеф-сафа кору урынына әйләнеп бара. Диндә бу рөхсәт ителәме? Мунча керү әдәбе нидән гыйбарәт?**

**Усад җирлеге «Ихлас» мәчете имамы Рузил хәзрәт ИХСАНОВ белән шул хакта сөйләштек.**

**:: Хәзрәт, мунча кергәндә дин ягыннан үтәлергә тиешле кагыйдәләрне искә төшереп үтик әле.**

– Ислам дине – әлбәттә, чисталык дине. Мөселманнарның Фикх китабында (хокук һәм бурычлары китабы. – **Ред.**) таһарәт, чисталык дигән аерым бер бүлек бар һәм ул беренче булып өйрәнелә. Моннан чыгып, без чиста йөрергә тиеш дигән нәтиҗә ясый алабыз. Чистарыну гыйбадәт һәм дога кылуның ачкычы булып тора. Таһарәтсез намаз укырга, Коръән китабын тотарга ярамаганлыгы турында да беләбез. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә: «Чисталык – иманның яртысы», – диелгән. Мөхәммәд (с.г.в) тешләрне чистарту, тырнак кисү, киемне юу турында да алдан әйтеп калдырган, тәнне чиста тотуны безгә боерык итеп йөкләгән. Чисталык дигәндә өс-башны да, тешләрне дә, тырнакларны да тиешенчә чистартуны күз алдында тотарга кирәк. Мөселманнардан начар ис килеп тормаса, гел хуш ис аңкып торса яхшы. Хәтта сарымсак, суганлы ризык ашаганнан соң мәчеткә кермәскә кушалар.

Мунчаның үз әдәпләре бар, алар турында еш кына оныталар. Беренчедән, мунча һәм бәдрәфтә намаз гыйбадәте һәм догалар уку рөхсәт ителми, чөнки бу урыннар чиста саналмый, әмма анда кергәндә һәрвакыт дога укып керергә кирәк.

Ул болайрак яңгырый: «Бисмилләһи. Әллааһүммә инни әгүүзү бикә минәл хубси үәл хабәәис». Тәрҗемәсенә килсәк: «Аллаһ исеме белән башлыйм. И Аллаһ, мондагы җен ирләрдән вә җен хатыннардан Сиңа сыенам!»

Икенчедән, мунчага һәм бәдрәфкә сул аяктан атлап кереп, уң аяктан чыгу хәерле. Өченчедән, гаурәт урыннары капланган булу шарт. Ялгызың булганда яки ир белән хатынга гына гаурәт урыннарын капламыйча, шәрә килеш мунча керергә рөхсәт ителә. Ир-егетләр аерым, хатын-кызлар аерым, әни белән кыз, әти белән малай, әби белән онык, апа белән сеңел мунча кергән очракта да гаурәт урыннары капланган булырга тиеш. Әйтик, 4–5 яшьлек баланы мунчага юындырырга алып керәсез икән, сезнең гаурәт урынныарыгыз күренмәсен. Бер җенестәге кеше белән керәсе, ә кечкенә, 4–5 яшенә җитмәгән балалар булса, ул чакта шәрә килеш тә ярый. Дүртенчедән, ир-атларның һәм хатын-кызларның бергә керүе рөхсәт ителми! Моннан тыш, Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Сезнең берегез юына торган урында икенчегез кечкенә ихтыяҗын эшләмәсен», – дигән. Мунчамы ул, душмы – мондый урында кечкенә йомышны үтәргә ярамый. Бу – әдәпсезлек билгесе. Һәр кеше мунчада юынгач, артыннан чистартып калдырырга тиеш.

**:: Мунча эчендә кәеф-сафа корып утыру рөхсәтме? Күпләр анда сыра, хәмер эчеп, ашап та утыра бит...**

– Шәригатебездә мунчада җыелып ял итәргә ярамый дигән тыю юк, хәтта киресенчә, Раббыбыз билгеләгән кысалардан чыкмыйча, хәләл рәвештә җанга-тәнгә ял бирүне динебез хуплый. Әмма алдарак китерелгән барлык кагыйдәләр дә үтәлергә тиеш! Гаурәт урыннар капланган, чисталык сакланган булсын. Мунчада сыра һәм башка хәрам эчемлек яки ризык кулланырга ярамый. Нинди генә хәләл ял итү чарасы булса да, ул безгә намазны вакытында башкарырга комачауламаска тиеш.

Илдар Мөхәммәтҗанов

**:: Ә мунчада ятышу турында диндә ни диелә?**

– Бу сорау бик тә четерекле. Аллаһның никах аша ир һәм хатынга биргән зур нигъмәте – җенси мөнәсәбәт. Җенси мөнәсәбәт хайвани рәвештә шәһвәтне басу, вакытлыча ләззәт алуга гына кайтып калмасын өчен, аның исламда билгеле тәртипләре, үз кагыйдәләре, хәтта кайбер чикләүләре дә бар. Изге ният, тиешле әдәп, махсус догасы белән кылынган якынлык – гади шәһвәт сүндерүдән изге гыйбадәт дәрәҗәсенә күтәрелә һәм кешегә аның өчен әҗер-савап языла.

Ислам күзлегеннән караганда, якынлык кылуда Коръән аятенә таянабыз. Аллаһ Раббыбыз әйтә: «Хатыннарыгыз сезгә игенлек урыны, үзегез теләгән яктан игенлекләрегезгә килегез! <...> Хатыннарыгыз белән эш кылганда яхшылыкны үзегез башлап кылыгыз, якынлык кылырга да үзегез башлагыз, бисмилла әйтегез, Аллаһтан изге бала сорагыз!» Никахлы ир белән хатынның бергә хәләл рәвештә мунчада, саунада якынлык кылуы динебез тарафыннан тыелмый. Тик, мәсәлән, юына торган урын белән мунчаның чабына торган урыны бер-ләшкән икән, анда якынлык кылыр алдыннан әйтеләсе доганы уку хәерле гамәл түгел, шуңа да, мунчага кереп якынлык кылу теләге булса, керер алдыннан доганы әйтү хәерлерәк. Якынлык кылу алдыннан ир белән хатын: «Бисмилләһи. Әллааһүммә җәнниб-нә-шәйтаанә вә җәнниби-ишшәйтаанә мәә разәкътәнә», – дисәләр һәм аларга бала насыйп булса, аңа шайтан зыян китерә алмас», – диде Пәйгамбәребез (с.г.в). Доганың тәрҗемәсе: «Аллаһ исеме белән. Йә Аллаһ, безне һәм безгә ризык итеп биргән баланы шайтаннан сакла». Әлбәттә, иман иясе өчен бу доганы яттан белү һәм куллану хәерле.

**:: Мунчада җеннәр яши, шуңа ялгыз кермәскә, диләр. Шулай ук кояш баегач та, төнлә дә мунча кермәскә кушалар.**

– Әйе, мунчада җеннәр оялаган булырга мөмкин. Алардан якты ут саклый һәм бәдрәфкә, мунчага кергәндә укыла торган доганы әйтеп керү хәерле. Ялгыз һәм кояш баегач, төнлә мунча керү ярамый дигәнгә динебездә дәлилләр очратканым булмады. Мунча керү вакытына килгәндә, нинди вакытта керсәң дә ярый. Тик шулай да намаз вакытында без мунча кереп ятарга тиеш түгел. Бу вакытта намаз уку хәерле.

Гыйбрәт ал!

## Бәхетлеме син?

Бервакыт бер бай кешенең өенә юлчы килеп кергән. Хуҗа кеше аны яхшы гына сыйлаган, кунак иткән. Аннан ул мосафирдан дога кылуын сораган. Бу исә бик хикмәтле мосафир булып чыга. Ул байдан: «Син бәхетлеме?» – дип сорый. Бай бу сорауга аптырап кала, аның әлегә кадәр бу турыда уйлаганы да булмаган икән бит! Моны күреп, мосафир: «Син бәхетсез икән», – ди дә өйдән чыгып китә. Шуннан байның тынычлыгы югала, ашаганы – аш, йокысы йокы булмый. Ул белгән кешеләреннән: «Бәхет нәрсә соң ул?» – дип сорашып та карый. Әмма һәр кешенең җавабы төрле була.

pixabay.com

Ахыр чиктә, җавап эзләп, ерак сәфәргә чыгып китә бу бай. Очраган бер кешедән бәхет турында сораша торгач, шәһәр читендә бер хикмәтле кеше яши, дип, шуңа барып карарга кушалар. Эзләгән кешесе, ул барып җиткәндә, агач күләгәсендә йоклап ята торган була. Бу кеше аңа: «Капчыгыңны куй да, мин сиңа бәхетнең нәрсә икәнен аңлатам», – ди. Бай капчыгын куюга, теге кеше аны тиз генә эләктереп, чабып та китә. Бернәрсәсез калган бай: «Алтыннарым, гаиләм, йортым бар иде, тыныч кына яшисе урынга, үземә маҗара эзләп йөрим», – дип, үзен тирги башлый. Йөри торгач, капчыгын табып ала. Ни гаҗәп, аның эчендә бер әйбер дә югалмаган була. Агач артыннан теге хикмәтле кеше килеп чыга да: «Бәхет ул – булган нигъмәттән канәгатьлек кичереп, шөкер итеп яшәү, синең бөтен әйберең дә бар иде, аның кадерен белми идең һәм моны югалткач кына аңладың», – ди.

Йәгез, бер дога!

## Йөкле хатын-кыз догасы

Карынында бала йөрткән хатын-кызга, мөмкинлек булган саен, «Аятелкөрси» һәм «Инширах» сүрәләрен укырга кирәк. Моннан соң йөкле хатын түбәндәге доганы укыса яхшы:

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.
Әллааһүммә әгътыйнәә сыйххәтән вә гаафийәтән вә әүләәдән саалихән вә ризкан вәәсиган вә дугаа-ән мәкъбүүлә».

**Мәгънәсе:** «Мәрхәмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән башлыйм. Аллаһым! Безгә саулык һәм сәламәтлек бир. Хәерле балалар бүләк ит, мул ризык биреп, догамны кабул ит, Аллаһым!»

**Белеп тор!**

**Рәкәгать** – намазның аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә куюны үз эченә алган бер өлеше.
**Сәнә** – мактау, мактап әйткән сүз.
**Сәхабә** – Мөхәммәд пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән кешеләр.
**Ләзем** – кирәкле, тиешле, зарур.
**Хилаф** – ярамаган, каршы, тискәре.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

## ГӨЛИНӘ ШӘЙХИ:

# «МИН ЯРАТУ ӨЧЕН ТУГАН»

**Шигъриятькә гашыйк, үзе дә шигырьләр язучы, аларны көнделдән-көнелгә барып җитәрлек итеп укучы, һөнәре һәм калебе белән актриса, «Китап» радиосының тапшырулар мөхәррире, ут янып торган Гөлинә ШӘЙХИ «Ни хәл?» сәхифәсендә кунакта.**

**:: Гөлинә, ни хәл?**
– Бүген яхшы, Аллаһка мең шөкер. «Ни хәл?» – дип сорар кешеләр барында хәл начар була алмый.

**:: Күпләр сине тавышыңнан танып, ишетеп белә. Ә чынлыкта кем ул Гөлинә Шәйхи?**
– Гөлинә Шәйхи... Кем дип әйтим? Артист? Гомеремне сәхнәгә багышламадым. Җәлләдем. Шагыйрә? Такташ һәм Гаташныкы шикелле үк көчле шигырьләрем юк. Тик шулай да, көнделемдәге хисләрне шигырьгә, җырга салып, шулар белән укучыларымны елата һәм уйландыра алам икән, димәк, бөтенләй үк өметсез дә түгелмен. Кем булсам да, кеше булып калырга язсын. Миңа шунысы мөһимрәк.

**:: Синең театр артистына укып, артист булып эшләп, бу һөнәрне радио алып баручысына алыштыруың билгеле. Ни сәбәптән шундый борылыш?**
– Бу минем сеңлемә биргән соңгы антым иде. Аның хакына мин бу адымны эшләргә тиеш идем. Тиеш идем! Чөнки сүз бирдем. Артык соңга да калдым, әмма вәгъдә – иман! Аннан соң радиода эшләү теләге белән мин күптәннән янып йөрдем. Казанда өр-яңа радио ачылачагын ишетеп белүгә, монда күчтем дисәм дә була. Җаңга шулкадәр якын «Китап» радиосының юлы минем белән башлануын теләдем. Һәм шулай булды да.

**:: Сеңлеңә биргән антың?.. Бертуганыңмы?**
– Юк, ул минем туганнан туган сеңлем иде. Әмма без аның белән бертуганнар кебек якын булып үстек. Бөтен серләр, хәтта хыяллар да уртак иде бугай... Ул миннән һәрвакыт үрнәк алды.

**:: Көнделеңне бушатып, тетрәнүләрең белән уртаклашасың килмиме?**
– Бу турыда минем беркайчан да ачылып сөйләшкәнем юк. Әле ул җөйләнмәгән яра – тимәсәм дә, каны саркып, иңрәп тора... Әмма вакыты җиткән бугай... Җанның тәүге тетрәнүе беренче мәхәббәт белән аерылышкач булды. Бик авыр кичердем. Шул ук елны бабайга инсульт бәрде, аның артыннан ук әбигә. Әби – бер ел, бабай ике ел урын өстендә ятты. Ул елны юньләп укый да алмадым. Ярты йөрәк алар янында иде. Куз алдыгызга гына китерегез: кайткан саен капка төбеннән үк «алма бөртегем кайткан» дип каршы ала торган әби бер мизгел эчендә тора алмас булды. Мине тәрбияләп үстергән әби бит ул! Хәйран озак ятты ул урын өстендә. Кайткан саен янына утырам да җыр сузам: «Бер кайтмасам, әнкәй, бер кайтырмын, утыңны сүндермичә мине көт». Ә аның күзеннән яшь ага. Югалту кыен булды. Ярты йөрәк өзелде. 2017 елның 2 гыйнварында – әби, нәкъ 14 көннән бабай китеп барды... Көнделдәге иң зур үкенеч, беләсезме, нәрсә? Яннарына ешрак кайтмавым. Вакыт юк, янәсе! Хәзер вакыт бар, алар юк!..

Икенче зур тетрәвем – 2018 елда, туган көнемә биш көн кала 20 яшьлек сеңлемсез калу. Авариягә очрап үлде... Җирне тырный-тырный еладым шул чакта. Тормышның асты өскә килде, сулу капланды, күкрәк тутырып, һава да алып булмый иде кебек. Әле дә үлемен кабул итә алмыйм...

Соңгы тетрәнү (соңгысы була күрсен берүк!) – әти. Ул өлешчә хәтерен югалтты. Бүген безнең кулдагы сабый бала кебек...

### Блиц-сораштыру

**– Көн ни өчен дә төн ни өчен?**
– Көн – дөньяны күрер өчен, төн көнделне тояр өчен.
**– Кара мәче юлыңны киссә, нишлисең?**
– Белгән догаларымны укыйм.
**– Бик нык ачу килгәндә...**
– ...мине тынычландыра алган берәү белән сөйләшәм.

**:: Сынаулар күбрәк көчлеләргә бирелә, диләр. Үксеп әрнегән чакларыңда син шигърияткә барып сыенасың бит?**
– Шигърият күбрәк яратудан туа, әрнүләрне дә үзенә сыйдыра белә. Ул – минем өчен көнделне бушату касәсе. Ярый әле каләмем бар да, ярый кайчандыр гашыйк булганмын, миңа язган юлны уза киләм, дим. Аларның барысы да, өлешчә булса да, кәгазьдә кала.

**:: Казанга күченеп килүгә сеңлеңә биргән вәгъдә генә сәбәпчеме? Әллә театрдагы рольләр кытлыгы, амбицияләр дә үз ролен уйнадымы?**
– Юк, рольләргә кытлык булмады, Аллаһка шөкер. Авыл – барыбер авыл инде ул. Казанга күчү теләгем зур иде һәм биргән вәгъдәм бар иде. Сеңлем укыйн тәмамлап, Казанга күченүгә, мин дә күчәм дигән идем. Җитешмәдем... Соңладым. Ә театр ул – һәрчак йөрәктә. Бөтенләйгә китмәдем дип уйлыйм. Уйналасы рольләр бар, язмышым булса, кире театр сәхнәсенә кайтырмын дип өметләнәм. Йөрәк теле белән әйтсәм: театрга мин кайтам әле!

**:: Ярату, мәхәббәт, бәйлелек, химия – бу сүзләрнең кайсы сиңа якынрак?**
– Һичшиксез, ярату. Дөньяны, кешеләрне, тормышны, якыннарны. Мин – ярату өчен туган кеше. Яратусыз тормышның ни икәнен белергә язмасын!

**:: Йөрәктәге иң татлы хыялың белән бүлеш әле, Гөлинә.**
**Газетабыз бәйгесе тарихын барлаганда, аның исеме аерым урын алып тора. Балтач батыры Айдар ХӘЙРЕТДИНОВ Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы көрәш турнирында 10 мәртәбә җиңү яулады. Шик юк, тагын да күбрәк була ала иде. Әмма ул 30 яшендә келәмнән китеп барды. Легендар көрәшче, бүген Балтач районы башкарма комитеты рәисе белән келәм тәрбиясе, җиңү бәясе һәм батырлык мәгънәсе турында сөйләштек.**

**:: Көрәштән китеп буламы?**

– Китеп булмый. Тормыш – үзе көрәш, ул – безнең яшәү рәвеше, дибез бит. Юктан гына әйтелгән сүзләр түгел бу. Аннары бүгенге вазыйфам да көрәштән китәргә мөмкинлек бирми. Әле бит өйдә ике малай үсә, көрәш белән шөгыльләнәләр. Киттем дип, келәм белән араны өзгән булсам, алар да милли спорт төрен үз итмәс иде. Шөкер, матур гына бил алышып йөриләр. Әле менә олысы күптән түгел генә республика ярышыннан өченче урынны алып кайтты. Кыскасы, ярышка йөрмәсәң дә, келәмгә чыкмасаң да, көрәштән аерылып булмый.

**:: Ярыш димәктән, келәмдә барысын да күргән батырга башкаларның бил алышканын күзәтү авыр түгелме?**

– Төрле вакыт була. Кайвакыт тавыш чыккан алышлар, бер-берсен хөрмәт итмәгән егетләр очрый. Әлбәттә, андыйларны карыйсы килми. Ә инде җиңәм дип чыккан, көндәшен дә, халыкны да хөрмәт иткән егетләрнең бил алышканын сөенеп карап утырам. Юк, үземне бүгенге көрәшчеләр белән чагыштырмыйм. Ник дисәгез, һәр кеше үзенең әзерлегенә, сәләтенә, хәтта тәрбиясенә карап көрәшә. Мин болай яки тегеләй итәр идем дигән сүз эш түгел ул. Мин көрәшкәндә дә килеп җитмәгән яклар булгандыр. Бил алышуым бөтен кешегә дә ошап беткәндер, дип әйтә алмыйм. Әйе, Муса Җәлил турнирын 10 тапкыр оттым, әмма җиңелгән вакытлар да булды. Сүз дә юк, келәмдә кемгәдер үпкә белдереп, кул бирмичә чыгып киткән вакыт булмады. Димәк, үзем эшләп бетермәгәнмендер, дип фикер йөртә идем.

> Тормышта да шулай бит: башкаларны өйрәтергә яратабыз. Әмма ул кешенең нинди юл үткәнен, нинди киртәләр аша узганын, ни өчен шулай эшләгәнен белмибез.

**:: Иртә киттем дип уйламыйсыңмы?**

– Шөкер, Ходай миңа зур җиңүләр насыйп итте. Китәр алдыннан гына билбаулы көрәш буенча дөнья чемпионы булдым. Келәмнән 30 яшьтә китү, бәлки, иртәрәк тә булгандыр. Әмма минем көрәштән тыш башка вазыйфа да бар иде. Әле менә бүген дә очрашуга килгәндә уйлап килдем. Беләсең бит инде, милициядә хезмәт иттем. Эштән сорап китәргә кирәк, ә анда төрле хәлләр була иде. Ел ахырында мәшәкате аеруча күп килеп чыга. Игътибар итсәң, Татарстан, Россия беренчелегендә җиңүләр саны азрак. Чөнки эш аркасында бармый кала идем. Ә бит иң көчле вакытлар бу. Башта тренировкага барасың, аннары рульгә утырып, Казанга чыгып китәсең. Атнасына биш көн шулай. Әле эштә дә җитәкчелек итәргә кирәк, кул астында 30дан артык кеше. Сорау алып утырганда йоклап киткән вакытлар бар иде.

Бары көрәш белән генә шөгыльләнсәм, бәлки, соңрак та китәр идем. Чемпион булгач, җиңеләсе килми бит. Моның өчен тагын да яхшырак әзерләнергә кирәк. Чөнки миңа каршы минем алымнарны махсус өйрәнеп әзерләнгәннәрен дә беләм. Җиңгәннәре дә булды, сүз дә юк. Ныклап әзерләнеп, үземне формада тоту авыр була башлады. Шуңа күрә келәмнән китүне дөрес дип санадым.

**:: Ә аннары барыбер кайттың бит.**

– Район җитәкчелеге сорагач, командага ярдәм итү өчен булды ул. Ике ярышка бару өчен. Әмма бу инде бөтенләй башка Айдар иде. Чемпион Айдарның чоры келәм белән саубуллашкач бетте. Көрәшкә кабат чыгу үземә дә авыр булды. Чөнки биргән сүземне бозарга туры килде. Шулай килеп чыга бит? Хәтта җиңгән булсам да, ул җиңүне башкача кабул итәр идем.

tatarstan.ru

### БЕЗНЕҢ БЕЛЕШМӘ

**Хәйретдинов Айдар Фоат улы. 1978 елда Балтач районының Нөнәгәр авылында туган. Көрәш буенча 7 мәртәбә – Татарстан, 5 тапкыр Россия чемпионы. Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган бәйгенең 10 мәртәбә җиңүчесе. Атказанган спорт остасы. Билбаулы көрәш буенча дөнья чемпионы. Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе.**

**:: Иң истә калган җиңү һәм җиңелүләр бармы?**

– Күңелемдә алай тасвирлап сөйләрлек вакыйгалар нишләптер күп түгел. Әлбәттә, Муса Җәлил турнирында беренче мәртәбә батыр калганымны хәтерлим. Җиңелүләргә килгәндә, әйтәм бит, димәк, үзем эшләп бетермәгәнмендер, дип фикер йөртә идем. Шулай да берсендә ни өчендер абсолют батыр исеме өчен көрәшмичә кайтканым истә калган. Бик озак үкендем мин аңа. Көчле вакытта көрәшергә кирәк.

**:: Айдар Хәйретдинов көрәшкән чор дигәндә бик күпләр Айрат Гыйлаевны да искә алачак...**

– Аны җиңү республика ярышын отуга тәңгәл иде. Келәмдә көндәш булдык, хәзер аралашып яшибез. Бер-беребезгә хөрмәтебез зур. Икебез арасындагы очрашуларның исәбен аерым санап бара идем. Бер-беребезгә лаеклы көндәшләр булдык, шөкер, бүген дә бар андый егетләр.

**:: Көрәштә үзгәрешләр булып тора, буыннар алмашына. Җиңүнең бәясе үзгәрдеме?**

– Һәр чорның үз батыры, үз көрәше бар. Көрәшчеләр һәрвакытта да ярышка әзерләнеп килгән, келәмгә җиһәм дип чыккан. Әйе, бүген үз тормышын профессиональ дәрәҗәдә көрәшкә көйләгән, язмышын шуның белән бәйләгән егетләр бар. Без бит әле ул чорда барыбыз да кайдадыр башка җирдә эшләп, аннары келәмгә чыгып бил алыша идек. Менә тагын бер истәлек: Муса Җәлил турнирын отып кайткан көнне төнгә патрульгә чыктым. Республика ярышын отканмын бит, ял да итәсе килгәндер. Юк, эшкә чыгасы бар! Бүген бары көрәш белән генә шөгыльләнүчеләр булганлыктан, бәлки, алар арасындагы алышлар кискенрәктер.

> Инде чагыштыра башласак, тагын бер мәсьәлә турында әйтми китә алмыйм. Безнең чорда махсус туклану, ягъни допингтан бик сирәк кеше генә файдаланганлыр. Бүген аның белән шаяручылар аз түгел дип беләм. Хәләл көч белән бил алыштык. Кеше ашаган бәрәңге ашадык без дә. Хәтерлим: келәмгә чыгасы көнне иртәнге ашка ярты телем ипи белән сыр калган. Шуны капкалап, мәчеткә кереп сәдака бирдек тә ярышка чыгып киттек.

**:: Сөйләшә торгач, көрәшнең тәрбияви ягына килеп чыктык бит әле. Егетләр аңлыймы үзләренең гади генә спортчы түгел, ә милләтнең сакчылары да булганнарын?**

– Бу мәсьәләдә эшләргә эш бар. Тормышның кыйммәтләре үзгәрә. Кеше, акча табылса, барысы да була, уңышка ирештем, дип уйлый. Үзебездәге тренерларга кабатлап торабыз: балаларның акыл ягын да үстерергә тырышыгыз, дибез. Аларга тәрбия дә кирәк. Бу юнәлеш аксамый дип әйтә алыр идек тә, тик келәмдә тарткалашу бик күп. Бер-береңә хөрмәт булырга тиеш. Батыр ул җиңүче генә түгел. Башкаларга үрнәк кеше дә. Үзен келәмдә генә түгел, аннан читтә дә бу исемгә лаек итеп күрсәтә белергә тиеш.

**:: Тәрбия эше белән шөгыльләнүчеләр арасында энең, танылган батыр, хәзер инде оста тренер Ринат Хәйретдинов та бар. Һәрвакыт синең белән чагыштыру комачау итмәде микән аңа?**

– Һәр нәрсәнең ике ягы була. Минем энекәш булу аңа кайдадыр ярдәм иткән, шул ук вакытта нәрсәдәндер тыелып калырга да мәҗбүр иткән булырга мөмкин. Тик минем исем аңа зыян китергәндер дип санамыйм. Шөкер, бер-беребезгә келәмдә дә, тормышта да ярдәм итеп яшибез. Бер кешене икенчесе белән чагыштыру дөрес түгел. Һәрберсе – аерым шәхес. Сәләте, физик мөмкинлеге, әзерлеге, характеры төрле була. Минем җиңүләр аңаниндидер уңай этәргеч биргәндер дип өметләнәм. Гаиләдә өч малай үстек. Башта абыебыз Айнур көрәшә башлады. Соңрак аңа без иярдек. Туганнар бер-берсенә көндәш була алмый. Безнең бәхеткә, әти-әниләрнең көрәшкә мөнәсәбәте дә яхшы булды, тренерлар да күп тырышлык куйды. Болар икесе дә бик мөһим. Тагын да сәләтлерәк булып та, төшеп калган егетләрне күрдем.

**:: Хәзер өйдә дә ике көрәшче малай үсеп килә. Аларны да исемнәре белән түгел, «Айдар малае» дип әйтәчәкләр. Барыбер чагыштырачаклар.**

– Бу хакта үзләренә дә әйтәм. Әле бит җитәкче малае дип тә бәяләячәкләр. Аларга мөмкинлекләр куелган, бурычлар билгеләнгән. Алар җиңүчеләр, безнең фамилияне данлаучылар, безнең көрәшне дәвам итүчеләр, аны үстерүчеләр булырлар дип өметләнәм. Үзләреннән тора, мәҗбүр итеп тә булмый. Әмма, яшермим, әти катылыгы бар инде. Шөгыльләнмичә генә уңышка ирешеп булмаслыгын белеп, Хәйретдиновлар фамилиясенең җаваплылыгын тоеп үсәләр. Шунсыз була да алмый.

**:: 2018 елда Балтач Сабан туенда баш батыр калдың. Тагын бер чыгып, осталыгыңны күрсәтү теләге юкмы?**

– Юктыр инде. Хәзер инде яшь тә бара. Әмма чыгып, көрәшеп, чирәмендә аунап, җиңү хисен тагын бер кичерәсе килә. Бөтен кеше дә шулайдыр ул. Дан-шөһрәт түгел, үзеңә ниндидер рәхәтлек алу өчен. Кайбер кеше тормыш тәмен башка нәрсәдән таба. Ә без ул тәмне тирләп, кайнап, көрәштә табып яшибез.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

**Узган еллар тормышыбызның аерылгысыз өлешенә әйләнгән «Инстаграм» челтәре белән хушлашып уздык. Күпләр аны иң якын кешесен югалткандай борчылып, хәтта елап (!) озатты. «Инстаграм» рәсми рәвештә бетәргә тиешле шул ук 14 март көнне ахырзаман җитәчәк, дисәләр, кешелек ул кадәр үк курыкмас иде, мөгаен. Һәрхәлдә, ниндидер бер чираттагы социаль челтәрнең бетүеннән шулкадәр трагедия ясаучыларын күргәч, әнә шундый тәэсир калды.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

# ХУШ, «ИНСТАГРАМ»! ИСӘНМЕ, «РОССГРАМ»?

### «Инстаграм»га алмаш килә

Билгеле булганча, күптән түгел прокуратура Роскомнадзор идарәсенә Россиядә «Инстаграм» челтәрен тыю таләбе белән мөрәҗәгать итте. Шул рәвешле «Инстаграм», «Фейсбук» һәм «Ватсап» челтәрләренә нигез салган Meta Platforms Inc. оешмасын экстремистик дип танырга җыеналар. Шушы хәбәр таралып, күп тә үтмәде, атна башыннан Россиядә «Инстаграм» челтәре тыелачагы билгеле булды.

Әмма безне моның ише чикләүләр белән генә куркытам димә. Фәлән кешенең нәрсә ашавын, нәрсә киюен, ничек ялын уздыруын белеп торырмын, кем белән очрашуын, ничек яшәвен хәзер каян белеп торырмын инде дип борчылган көннәрдә бер җае чыкты тагын. Безнең илдә тыелган сайтларны «эһ» тә итмичә ачарга ярдәм иткән VPN кушымтасы барлыгын белеп алгач, «Инстаграм»га шыпырт кына әнә шуннан керә башладык. Аның ышанычлымы-юкмы икәнлеген дә тикшереп торыш юк. Аннан файдаланган кешеләрне җинаять җаваплылыгына тартачаклар икән дигән имеш-мимешләрне дә колакка элмәскә тырышабыз. Көндәлек юлдашыбызга әверелгән «Инстаграм»нан гына аерылмыйк!

«Аудит һәм куркынычсызлык» консалтинг оешмасы башлыгы Марсель Закиров сүзләре белән әйтсәк, безнең илдә социаль челтәрләрне ил күләмендә интернетны өзгән очракта гына чикләп була. «Бездә теге яки бу социаль челтәрне тулысынча ябып булмаганын аңладык инде. Моны ил күләмендә интернетны өзгән очракта гына эшләп булачак», – ди ул.

Гаилә психологы Альбина Вәлиуллина халыкның бу очракта үзләрен шул рәвешле тотуына әллә ни гаҗәпләнми.

– Ике елдан артык пандемия шартларында яшәгән, хәзер инде килеп туган бүгенге катлаулы вазгыятьтә, билгесезлектә яшәгән күпләр «Инстаграм»ны яраткан, ышанычлы дусты, ял итү урыны кебек кабул итә иде. Баланың уенчыгын тартып алганда сабый ничек борчылса, күпләр ияләнгән социаль челтәре белән хушлашуны да шулай авыр кичерә, – ди психолог. – «Инстаграм» ябылу бигрәк тә үсмерләр, яшьләр психикасына бәрәчәк. Аңа кадәр күпләрнең яраткан «ТикТок» челтәрен дә чикләделәр бит. Бүген, нигездә, социаль челтәрләрдә яшәгән, тере аралашуның нәрсә икәнен белмәгән, чынбарлыкны виртуаль дөньяга алыштырган яшь буын өчен бу – бик зур шок, билгеле. Әмма аларны бу гадәтләреннән арындырып булмас инде. Болар булмаса, башка социаль челтәргә күчәрләр дә шул ук виртуаль дөньяда яшәвен дәвам итәр алар.

Яңа димәктән, тиздән Россиядә «Инстаграм»га алмашка «Россграм» дигән яңа социаль челтәр барлыкка киләчәк дип ышандыралар. Әлеге хәбәр проектның рәсми сайтында басылган. Социаль челтәрне «ВКонтакте» белән «Телеграм»ны оештырган Павел Дуровның төркемдәше Александр Зобов эшләгән. Ул быелның 28 мартыннан эшли башлар дип көтелә. Аңа башта топ-блогерлар һәм партнерлар керә алачак. Гади кулланучылар исә аңа апрель аенда тоташа башлар дип көтелә.

### Ышаныч ташка үлчим

Дөрес, әлегә «Инстаграм» социаль челтәрендә VPN дигән махсус кушымта аша утырып була, дип тынычландыралар. Әмма соңгы арада моның өчен җинаять җаваплылыгына тартачаклар икән дигән имеш-мимеш тә таралды. Бу – ни дигән сүз? VPN кушымтасы аша «Инстаграм»да утырган кешеләргә, дөрестән дә, җинаять җаваплылыгы янамы? Юрист Роман Архипов фикеренчә, әлегә телефоннан «Инстаграм» кушымтасын бетереп атарга кирәкми.

– «Инстаграм» белән хәзер VPN кушымтасы аша иркен рәвештә файдаланырга мөмкин. Бүген моның өчен берничә җәза да янамый. Оешма Югары суд карары нигезендә генә экстремистик дип таныла ала. Ул исә әлегә прокуратура таләбен карамады. Өстәвенә әлеге оешмаларның Россия территориясендә үз вәкилләре һәм юристлары бар. Суд утырышында алар да катнашачак. Meta Platforms Inc. оешмасын экстремистик дип танырлар дип уйламыйм. Моны үзенә күрә бер куркытып алу галәмәте генәдер дип саныйм. Әмма аны экстремистик дип таныган очракта да бу гади социаль челтәр кулланучыларга кагылмас, мөгаен. Шуңа күрә тагын бер кабатлыйм: әлегә VPN кушымтасы аша «Инстаграм»да курыкмыйча утырырга мөмкин. Алга таба нәрсә булачагы Югары суд карарыннан тора, – ди белгеч.

«Ярамыйга карамый» шигаре белән эшли торган һәр нәрсә күңелдә барыбер шик уята. Ничек кенә тынычландырырга тырышсалар да, тыелган сайтларга җәйлы гына керергә мөмкинлек биргән VPN кушымтасына ышаныч ташка үлчим. Соңгы арада телефонына шушы кушымтаны йөкләткән кешенең смартфонына вирус кереп, онлайн банк кушымтасындагы акчасы да юкка чыгарга мөмкин икән дигән имеш-мимешләр ишетелә башлады. IT-куркынычсызлык буенча белгеч Максим Ибатуллин да VPN кушымтасы белән эшләгәндә сак булырга киңәш итә.

– Әлеге программа зыян китермәсен дисәң, аны ышанычлы, билгеле чыганаклардан гына йөкләтергә кирәк. Кушымтаның рейтингына да игътибар итегез. Ул никадәр югарырак булса, программа да шулкадәр ышанычлырак дигән сүз. Юкса хәзер күпләр, аны-моны уйлап тормыйча, VPN кушымтасын каян туры килсә, шуннан йөкләтә. Бу бик куркыныч. Шикле чыганактан йөкләткән кушымта, телефондагы бөтен логин-парольләрне җимереп, шәхси мәгълүматларны, хәтта онлайн банктагы акчаны да җилгә очырырга мөмкин. Мошенниклар бу очракта да үзләренә файда эшләп калырга тырышыр ул, – дип кисәтә белгеч. Шуны истә тотып, Роскомнадзор идарәсе дә үзебезнең «ВКонтакте», «Одноклассники» челтәрләренә өстенлек бирергә киңәш итә.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә VPN кушымтасына да көн бетә башлады. Роскомнадор идарәсе әле күптән түгел генә берьюлы 20ләп популяр VPN сервисын чикләгән.

### Сабырлык сорала

«Инстаграм» челтәренең ябылуы күпләргә «Татар малай» булярак таныш Ринат Галиәхмәтов өчен көтелмәгән хәл булмаган. «Өч ел элек «Телеграм» белән дә шундый ук хәл күзәтелгән иде инде. Ябабыз, диделәр дә япмадылар. Анда да кешеләр VPN кушымтасы аша керде», – ди Ринат. «Инстаграм» ябылу турында имеш-мимешләр таралгач та, язылучыларына әнә шул кушымтадан файдаланырга киңәш иткән ул.

Бүген Ринат Галиәхмәтовның биредәге сәхифәсен карап баручылар саны шактый кимегән. Көндәлек сторисларны күзәтүчеләр, әйтик, 50 процентка азайган. «Хәзерге вакытта «Инстаграм»да булган мөмкинлекләрдән файдалана белә торган, актив кулланучылар гына калды. Реклама кимеде. Алдан килешеп куелган рекламалар хәзер куелып бетә дә, алга таба ни буласын әйтә алмыйм. Тәкъдимнәр бар, әмма хәзер алар күбесенчә, син – миңа, мин – сиңа принцибы белән – бартер рәвешендә генә булыр, мөгаен. Тере акча белән эшләү кимер дип уйлыйм», – ди ул.

«Инстаграм»га ясин чыгарга әзерләнгән көннәрдә якыннары белән элемтәне югалтырга теләмәгән һәркем «ВКонтакте» челтәрендә аккаунты барлыгын искә төшерде, «Телеграм» каналын булдырды. Алар әлегә иң ышанычлы каналларның берсе санала. Ринат Галиәхмәтов исә соңгысын әллә ни үз итеп бетерә алмаган. «Телеграм» – «Ватсап» кебек үк бөтенләй башка система. Анда музыка, рецептлар белән бүлешә торган төркемнәр алып бару җайлы. Әмма анда үзеңнең шәхси сәхифәңне алып бару бик авыр. Язылучыларым арасында уздырган сораштыру да күпләрнең «ВКонтакте» челтәренә өстенлек бирүен күрсәтте», – ди ул.

Игътибар иткәнсездер, халык күпләп «Телеграм»га күчә башлау белән бу кушымта чүп оясын хәтерләтә башлады. Бер белмәгән кешеләр сине үзенең биредәге төркеменә, каналына кушып куя. Шул рәвешле син, телисеңме-теләмисеңме, дистәләрчә «Телеграм» каналда утырасың булып чыга. «Бу күренеш үземә дә ошамый. «Телеграм»да шундый функция бар: кеше бер тапкыр сезнең белән аралашып, номерыгызны саклап калган булса, ул берьюлы берничә кешене үз төркеменә кушып куя ала. Еш кына сез үзегезне анда кемнең кушканын да белмисез. Аны берничек кисәтеп тә булмый. Сабыр итәргә генә кала», – ди Татар малай.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

**Фикер**

**Мәрьям МИҢНЕГУЛОВА, аш-су блогеры (Азнакай районы Мәндәй авылы):**
– Бу хәбәргә, бер караганда, сөендем, бер караганда, көендем дигәндәй. Күп вакыт телефонда уза, авыл кешесенең эше болай да тыгыз. Җитмәсә, хөкүмәт эшендә дә эшләгәч, вакыт җитми иде миңа. Ярар, гаиләмә күбрәк вакыт калыр, дидем. Барыбер ияләнгән гадәт белән «Инстаграм»ны ачасы килә, анда керергә теге юлын, бу юлын эзлим. Ни дисәң дә, монда никадәр тырышып җыйган язылучыларым, күпсанлы рецептларым бар бит.

**Гөлназ ГӘРӘЕВА, укытучы (Мамадыш районы Көек Ерыкса авылы):**
– Минем тормышымда «Инстаграм» бик зур роль уйнамый иде. Шуңа күрә ниндидер үзгәреш булды дип әйтә алмыйм. Файдалы киңәш булса, матур каналы сүзләр, күңелгә ятышлы шигырьләрне карап бардым, билгеле. Мин күбрәк «ВКонтакте»дагы сәхифәмдә утырам. Ул социаль челтәр миңа якынрак, сәбәбен дә әйтә алмыйм. Миңа калса, кулланыр өчен социаль челтәрләр бар. Шуңа тагын берсе барлыкка килсә, зур шатлык булыр дип уйламыйм.

# ФЛЮРА СӨЛӘЙМАНОВА:
# «БУЙ ҖИТМӘСЛЕК ҖЫРЧЫЛАР ЮК»

**Флюра апа: «Мин әзер, балам», – дип каршы алды. Чәчләрен килешле итеп тараган, иннек-кершәнен сөрткән, елмаеп басып тора. Сиксән яшьлек юбилееннан соң берни дә үзгәрмәгән кебек. Бар да элеккечә, аяклар гына хыянәт итә, ди ул, таягына ымлап. Йөзендәге караңгы болытлар исә ничек кинәт барлыкка килгән булса, шулай ук юкка да чыга. Флюра апа, Әлфиям тәрбиясе дип, балалары дөньясына алып кереп китә. Әңгәмә бәхет, кадер, тәрбия мәсьәләләре белән башлана.**

**:: Флюра апа, нәрсә ул кадер? Сез аны ничек аңлыйсыз?**

– Минем гомерем кадердә узды. Кая гына барсам да, кадерләделәр. Күп кеше бит юкса, кадерсезләделәр, дип зарланды. Гастрольләр белән авылларда йөргәндә дә үзләренә керткән һәрбер йортта игътибар, хөрмәт тойдым. Кадерне ничек аңлыйсың бит аны.

**:: Ә Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова кадер күрдеме?**

– Нишләп күрмәсеннәр ди?! Алар икесе дә егет булды. Азрак игътибар кимесә, үзләренә дигәнне ялап ала иделәр.

**:: Икенче яктан, рус эстрадасы шәхесләре зур зиннәтле сарайларда яши, безнең шәхесләребез шәһәрнең гап-гади фатирларында...**

– Менә син кадерне матди бизмәндә үлчисең. Ә мин аны башкача кабул итәм. Ул кешенең үзеннән тора. Матди хәрлеккә омтылганнар бездә дә ким яшәми. Мин исә андый бурыч куймадым. Аның шул ягы да бар: матди як олайган саен, рухи як тарая. Бай тормышта яшәгән җырчылар халыкка барыбер якын була алмый.

**:: Эстраданы, яңа исемнәрне күзәтеп барасызмы? Өметле җырчылар күпме?**

– Матур тавышлы җырчылар бар, әмма буй җитмәслек дип әйтерлекләре юк. Кайсының тавышы бик көчле, әмма җылылыгы юк. Ул булмаса, тамашачыга якынаеп булмый. Минем дә әллә нәрсәм юк инде, нишләптер халык яратты. Туксанынчы дистәне ваклаганда да сәхнәдә җырладым әле. Аягүрә басып җырлап булмады, урындыкка утырып чыгыш ясадым. Халык аягүрә алкышлады. Һаман яраталар икән. Аларның яратуы минем яшәтә. Авырып китсәм, улым Булат, сиңа концерт куярга вакыт җиткән, ди. Сәхнә чирне, вакытны туктата бугай ул, чынлап та. Анда хәтер дә, тавыш та нәкъ элеккеге кебек ачыла. Хикмәт ул.

**:: Җырчыны халыкка бер җыр таныта, диләр. Сезнең өчен ул кайсы җыр иде?**

– «Әниемә» җырыдыр, мөгаен. Аны һаман көтеп алалар бит. Әле менә Рәшит Ваһапов концертында да шушы җырны башкардым. «Ул җырның сере нидә?» – дип һаман сорыйлар инде. Кемдер, ятимлек ачысын татыганга моңлы башкарасың, ди. Кемдер башка сәбәпләрен күрә.

**:: Казахларда, үзбәкләрдә дә популяр җыр саналган «Әниемә» дигән җырның тарихын сөйләгез әле.**

– Ул чакта бит үзеңнең җырчы икәнеңне раслар өчен җиде кат тиреңне түгәргә кирәк иде. Союз буенча гастрольләргә чыгар өчен «СССРның эстрада сәхнәләрендә чыгыш ясау хокукы бирела» дигән таныклыкка ия булу кирәк. Ул – үзе бер тормыш имтиханы. Менә шул таныклыкны алгач, алтмышынчы елларда Казахстанның Актүбә һәм Алма-Ата дәүләт филармониясенең татар бригадасында эшли башладым. Казахстанда өч ел яшәдем мин. «Мәк чәчәге», «Истә, һаман да истә», «Тамчылар тамар чаклар», «Йөрәк сере», «Гүзәлия», «Алтын-көмеш», «Оренбур шәле» кебек җырлар шул елларда танылды. «Әниемә» җырын миңа композитор Шәмши Калдаяков үзе алып килде. Мин аны башта казах телендә җырлап йөрдем. Аннары, Казанга кайткач, Госман Әхмәтҗанов татарчага тәрҗемә итте. Шәмши үзе, син таныттың бу җырны, дип әйтә иде. Хәзер казах яшьләре бу җырны янә күтәреп алган икән. Бу табигый да. Әниләргә булган бөтен ярату, наз, аларның олы хезмәтен аңлау – бар да бар бит анда. Әйтсәм әйтим инде, профессиональ сәхнәдә чыгыш ясавыма алтмыш елдан артык. Шул дәвердә башкарган барлык җырларны әниләргә багышладым.

«Татар-информ»

**:: Флюра апа, хатын-кыз җырчыга танылу ансат түгелдер. Сезне кабул итәләрме? Тәнкыйть ишетеп, күңелегез сүрелгән чаклар булмадымы?**

– Туксанга җиткәндә зарланып утыру килешмәс инде. Тәрлесе булгандыр. Хәзерге гомер үреннән артка борылып караганда, мине күреп алучылар, ярдәм итүчеләр күбрәк булган дим. Гани Вәлиев, Усман Әлмиев, Сара апа... Санап бетерерлекмени аларны?..

**:: Сара Садыйкова: «Флюраны сәхнәгә мин алып чыктым», – дип әйтә торган булган. Сара апа булмаса, җырламас идегезме?**

– Хак әйткән Сара апа. Мин бит авылда тугызынчыны бетергәч тә Казанга киттем. Киез итек фабрикасына эшкә урнаштым, шул ук вакытта кичке мәктәптә укуымны да дәвам иттем. Җырлыйсым да килә иде. «Нишләп музыка буенча укырга кермәдегез?» – дип сорыйсың килә инде. Аннан кайда яшәр идем соң? Ә «Татваленки»ның тулай торагы бар иде. Авылда үземне белгәннән бирле җырлаганга, Горький клубына килдем, шунда Сара Садыйкова хорына эләктем. И, авылда кызык иде ул! Берне генә җырлыйм дип чыгасың да, шуннан кертмиләр инде. Ике дә була, өч тә. Авыл кешеләре елап тыңлыйлар иде.

Сара апа таләпчән, кырыс, җор телле иде. Азрак кычкырыбрак җырласаң, Флюра бигрәк акырып җырлый, дип әйтеп куя иде. Хәзер телевизорны ачар хәл юк, бөтенесе акыра, абау. Сара апа хорын мин эче тулы сандык дип әйтә идем. Әллә нинди хикмәтләр чыгарып була иде ул хордан. Сара апа исә бу яктан консервативрак. Ул моң яклы булды. Азрак хикмәт сизелгән җырчыларга махсус җырлар язып, аларны олы сәхнәләргә чыгарды. Мине дә бит Гани Вәлиев бригадасына ул алып барды.

**:: Сара апа үзе дә кагылган шәхес бит ул.**

– Сара апа көчле хатын-кыз иде. Көчле кеше беркайчан да, мине танымадылар, күрмәделәр, дип әйтә алмый. Аның аңа көче җитми.

**:: Сез, биш бала, ятим үскәнсез, дүрт балага үзегез әни булып килгәнсез. Балалар сезгә рәхмәтлеме?**

– Нишлисең бит, безнең буынны сугыш ятим итте. Әнинең чалымнары күз алдында торса да, әтине бөтенләй хәтерләмим, ул чакта миңа нибары 4 яшь булган. Әтием Зыятдин сугышның беренче елларында ук һәлак булган. Озак та үтми, абыйны да фронтка алганнар. Аннан соң озак тормады, биш баланы ятим калдырып, әни дә гүр иясе булды. Безне олы абый үстерде. Сеңлебез Фәниягә 2 яшь кенә булгач, безне ятимнәр йортына алып китмәкче булдылар. Ярый әле әнинең сеңлесе каршы төште. Юкса кайсыбызны кая таратып бетергән булырлар иде. Рәхимә апа әби-бабайлардан калган төп йортта яши иде, ятим калгач, без дә шунда күчендек. Ул авылда тракторчы иде, кулы каты, холкы кырыс. Үскәндә төрлесе булгандыр инде, хәзер рәхмәтле мин аңа.

> Мин беркайчан да әнисез үстем дип кычкырып йөрмәдем. Мәгәр андый балаларга ана назын бирү теләгем зур булды. Дүрт бала белән тол калган иргә кияүгә чыктым. Габделхак балаларга, Флюрага әни дип әйтәсез, дип бик каты торды. Ә мин, әни бер генә була ул, ирексезләмик, дидем. Шуннан балаларым да, хәзер оныклар да миңа дәү әни дип дәшә башлады. Бу – бик зур хөрмәт, ихтирам билгесе.

Әйтәм ич, ятимлекнең ачысын үз җилкәмдә татыдым. Шуңа күрә бу балаларның күңеле китек булмасын иде дип теләдем, тормышлары бөтен итәргә омтылдым. Шулай итеп, бала шатлыгы – минем шатлык, алар хәсрәте минем хәсрәт булды. Улым Маратны көтмәгәндә, уйламаганда җирләү барыбызга да олы кайгы китерде. Нишлисең бит, җыяр ризыклары беткән булгандыр... Булатым, олы кызым Алсу, Әлфия – барыбыз да бу хәлләрне бик авыр кичердек. Бүген Әлфиямдә яшим. Оныкларым хәлемне белешеп тора. Әле менә туган көнемдә, син безнең «главный» кешебез дип котлап киттеләр. Салих, Кәрим, Зилә... – алты оныгымның барысы да татарча әйбәт сөйләшә, Аллага шөкер!

**:: Габделхак абый, җитәр инде, син өйдә кирәк, дип әйтмәдеме соң?**

– Беркайчан да алай әйткәне булмады. Берәр җиргә гастрольгә барасы булса, озата бара иде. Бригададагы егетләр, без дә хатыннарны шулай озатып йөрсәк, кызык булыр иде, дип көләләр иде. Гармунчы Флера Хөрмәтова, балалы кешегә кияүгә чыгарга курыкмадың, син молодец, дип еш әйтә. Мин кадердә, ул ялгыз... Әгәр үзем генә булсам, нишләгән булыр идем икән, белмим. Балалардан куркырга, үзеңнекенә, үзеңнеке түгелгә бүләргә кирәкмидер ул. Әниләрен аңламаган балалар да, балаларыннан золым күргән ата-аналар да шактый бит, үз каннары булса да. Хикмәт сабый күңеленә ачкыч ярата белүдәдер.

**:: Без бик катлаулы заманда яшибез. Аны исән-сау кичәр өчен халыкка нинди киңәш бирер идегез?**

– Бер кешегә яраган киңәш икенчесенә ярамый, шулай да, сабыр итәргә кирәк, дим. Бәргәләнсәң, акыл арткы планга күчә. Хисләр башка чыкса, бик яман булыр.

**:: Телевизор карыйсызмы, Флюра апа?**

– Спорт каналларын карыйм, башкасын юк. Эстрада каналларын карамыйм, алар бигрәк тозсыз. Әйтәм бит, җырчыларны берсеннән берсен аерып булмый. Бер төрле кыяфәт, бер төрле тавыш. Элеккеге җырчыларны бер-берсе белән бутап булмый иде. Әйтик, Римма, Әлфия, Хәмдүнә, Илһам, Зөһрә – бутап буламыни аларны! Һәркайсы үзенчәлекле, үзгә холыклы, аерым манералы. Булсаң, шулай булырга кирәк инде ул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

## ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ

# СОВЕТ МУЛЛАСЫ

ХИКӘЯ

< Ахыры. Башы 25 февраль, 4, 11 март саннарында

– Менә бу сиңа Ходай бүләге шикелле инде...

– Әйтмәсәнә...

Икенче көнне, тәһарәтләнеп чыккач, Гарәпша карт ап-ак күлмәген, аның өстеннән буй-буй рәсем төшкән кәчтүмен киеп җибәрде, баш түбәсенә түбәтәе менеп кунаклады. Мәрзиянең оныгы Рәмис килгән төшкә ул тач егетләр сыман капка төбендә аны сабырсызланып көтеп тора иде. Урамнан барганда да кызурак атларга тырышты, кыяфәте горур, әйтерсең, теге вакытта барып җитә алмаган Берлинны алган!

Исем кушу йоласы тәмам булгач та, табыннан торып, Гарәпша мулла кайтырга ашыкты. Мәрзия, бер төенчеккә төйнәп, өстәлдәге ризыклардан савым җыеп, картның кулына тоттырды. «Шәмсекамәр белән чәй эчәрсез, миннән күп сәлам әйт үзенә», – диде Мәрзия.

Урамга аны озатырга Рәмис белән бергә Лилиянең әтисе Рөстәм дә ияреп чыкты.

– Рәхмәт, Гарәпша абый, коткардың! Күрәсең бит, апалар да чакырулы иде, Ульяннан тиклем эшләрен ташлап кайттылар, кирәк-ярагы да алынган...

– Барысын да үз вакытында эшләргә кирәк шул, Рөстәм нанам. Фарух хәзрәтнең кинәт авырып китәсен кем белгән?! Хәлләре әйбәт кенә микән, ишетмәдеңме?

– Ишеттем, әйбәт диделәр.

– Ярый алайса. Хәзер документларында да исемен үзгәртергә онытмагыз, документсыз беркая да барырлык түгел... Менә мин дә, анда-монда барып йөрмәсәм дә, әледән-әле тартмадан алып, паспортымны караштырып чыгам. Кырык бишь яшем тулгач алмаштырган идем. Андагы рәсеме шул ук. Ачып карасаң – миңа бер тамчы да охшамаган, ят кеше карап торган төсле. Туксанга җиткәндә кеше үзгәрә икән ул. Ә паспорт гел шул. Әллә, мин әйтәм, хөкүмәт минем бу кадәр яшәвемә өметләнмәгән, шуңа күрә кырык биштә паспорт алмаштыруны җитәрлек дип санаганмы?

– Анысы хак инде, минем әнинең дә шул ук хәл... Хәер, паспорт ул кәгазь кисәге генә, иң мөһиме – кушылган исем Аллаһы хозурына барып ирешеп, кызыбыз сырхаулардан арынсын иде.

Муллага хөрмәт зур, ә менә хатынына ничектер үзгә төрле карыйлар. Әйтерсең, абыстай ул, сәдака акчасын санап, шуның хисабына балда-майда йөзеп яшәп ятучы бер хан кызы! Булырсың монда хан кызы! Мулланы кем карый, кем өсбашын барлый, тамагына ашата... Шөкер, беркайчан да икәүләшеп, агылый белән тагылый төсле, кеше котыртып йөрмәдек.

– Әгәр хатыннарны акылына карап сайлый торган базар булса, сине бик кыйммәткә сатып булыр иде, карчык.

– Әллә син дә акылыма карап өйләндеңме үземә?

– Башка карар нәрсәң булмагач, соң...

– Ярый, йокла, ял ит. Иртәгә зур эш көтә үзеңне. Тансыклагансыңдыр ашларга йөрмичә.

– Тансыкладым... Бер күнеккәч, сагындыра икән шул.

– Борчылма, ирешер, Аллаһы боерса... Мин указлы мулла түгел дә үзе...

– И, Гарәпша абый, бөтен дөньясында, Алла юк, дип кычкырган вакытта муллалык эшен алып барган кешегә нинди указ кирәк булсын ди?! Ихласлыгың белән йөрдең бит!

– Шулай, ихласлыгым белән. Дәүләткә ачуым юк, берсе дә килеп, ник дога укыйсың, дип тиргәмәде. Шуңа күрә, алай, күкрәк киереп, кырыс заман мулласы мин диярлегем дә юк. Әмма моңарчы да, бүген дә бар укыганым ихлас иде. Хилафлыклары да киткәндер. Анысы өчен Ходай Тәгалә каршында җавап тотармын. Мин бит шул элеккеләр өйрәткән сабак белән генә хәзрәт эшенә төшенгән кеше...

– Анысы түгел, совет заманында да иманлы авыл булуыбыз мөһимрәк, Гарәпша абый!

Кичен яткач та, Гарәпша карт янында яткан карчыгына дәште:

– Менә, күрдеңме, карчык. Муллалыктан киткәч тә, ике ел буе Ходай шушы бүгенге исем куштыру өчен саклап тоткан икән бит мине. Биш ел элек тә мин кушкан идем бит, шул хатамны төзәтү өчен ярымсукыр көе Җир йөзендә яшәткән.

– Һай, карт юләр, тагын шул шыңгырдавыгыңны башладыңмыни?! Ул авыр исемне син такмадың, ата-анасы әйткәнне генә бала колагына пышылдадың бит! Хата диярлек кай җире бар моның?

– Наданлыгым белән аларны төзәтеп җибәрә алмаганмын. Анысы гөнаһ түгел. Алай да, иртәгә үк кәфенлегемне барла, яме. Менә-менә, Җир йөзендә башка эшең калмады дип, Ходай үз янына чакыртыр төсле... Мин үлгәч, берәрсенә кияүгә чыгарсың инде, шулаймы?

– Чыгам, берүзем салкын сәкедә ятыйммыни? – Иренең төртмәле сүзләренә Шәмсекамәр күптән күнеккән, ул башлаган уенны һәрвакыт дәвам итәргә әзер тагын үзе.

– Чык, хәзер инде миңа үкенечле түгел. Безнең авылда сиңа тиң карт-коры гына юк шул... Тапсаң да, ачуланмыйм, теге дөньяда һәркем беренче никахына кайта икән, анда да ирле-хатынлы булырбыз...

Ләкин Ходай Гарәпша картны үз янына чакыртырга ашыкмады. Ул туксанын да тутырды, әледән-әле үз янына кергәләгән Рәмистән Лилиянең сәламәтлеге хакында сораштырып торды. Кызның рәтләнеп китүен ишетеп, чын күңелдән шатланды. Туксан яшьлегенә силсәвиттән, районнан ук килделәр, Ельцин-Елсун үзе имзалаган котлау хатын кычкырып укыдылар. Һай, күңеле үсте дә инде аның шул вак кына әйберләргә! Күпме генә сүксә дә Елсунны, барыбер тегесе Гарәпшаны котларга җаен тапкан бит! Тик, аннан да бигрәк, хәзер инде Лилия атлы кызның тернәкләнеп китүе җанын җылытып торды. «Әле бик тиз генә үләргә җыенган идең, туксанны да уздың, йөзне дә ваклыйсың», – дип үзен чеметкәләгән карчыгына Гарәпшаның җавабы да әзер иде. «Бусы аның, карчык, муллалыкта намуслы хезмәт иткән өчен үзенә күрә Ходай Тәгалә биргән пенсия. Акчалата түгел, гомерләтә...»

2022 ел, Казан

**Сиренә ГАТИЯТОВА**

## КӨРӘШ

*Алдың да мине кочакка,*
*Ычкынып булмый һаман.*
*Холкыңны да әйтер идем...*
*Кешенекеннән яман.*

*Көйләп-чөйләп торгангамы,*
*Сагыз кебек ябыштың.*
*Катырак торасым калган,*
*Йомшак булдым... Ялгыштым.*

*Башкалардан ярдәм көтмим,*
*Тырышасы үземә.*
*Җиңгән кыяфәт чыгарып,*
*Карап торма күземә.*

*Төчкергәнне-йөткергәнне*
*Чүпләп кенә торасың.*
*Чир дигәч тә... Әрсезләнмә.*
*Нигә авыз ерасың?*

*Ничә тапкыр каты кыскан*
*Чагыңны онытмадым.*
*Көч җиткәнчә*
*тарткалаштым,*
*Ярарга тырышмадым.*

*Йомшарыр әле кочагың,*
*Ычкынып, йөгерермен.*
*Синдәйләрдән ерак качып,*
*Яшәргә өлгерермен!*

## ХИСАП

*Мин беркем дә була алмас идем,*
*Гүзәл җирдә туып үсмәсәм.*
*Моңлы итеп җырлар идеммени,*
*Изге чишмә суын эчмәсәм.*

*Елмаюдан ташып тормас идем,*
*Матурлыкны күрә белмәсәм.*
*Бүгенгемә шөкер итмәс идем,*
*Авыр сынауларга түзмәсәм.*

*Хыялларым чынга ашмас иде,*
*Бу тормыштан кызык тапмасам.*
*Итәгемә ябышырга торган*
*Начарлыкны этеп, качмасам.*

*Мин ул мин дә була алмас идем,*
*Җебеп төшсәм. Каты тормасам.*
*Омтылышлар белән яшәмичә,*
*Гел киресен генә уйласам.*

*Үз-үземә хисап тотмас идем,*
*Уйланырга сәбәп чыкмаса...*
*Яшәү матур була аламыни,*
*Исән чакта йөрәк йокласа...*

**P.S.** *Газетаның 4 март санында Сиренә Гатиятованың шигырьләре башка автор исеме астында бирелгән. Техник хата өчен гафу үтенәбез һәм яңа авторыбызга иҗади уңышлар телибез.*

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

# БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

**Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте**

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
**I урын – 10 мең сум;**
**II урын – 7 мең сум;**
**III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.**
**Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.**

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

**БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:**
«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

# Шаяннар иле

Без шаяннар илендә яшибез. Кеше бер-берсен шаяртырга, кызык итәргә ярата. Әле күптән түгел генә Казанның бер супер-пупер кибетендә шундый хәл булган. Һәртөрле маскарад киемнәре киенгән яшьләр кибет янында бер кешене эләктереп алалар да болай диләр:

– Безнең кибеттә бүген акция уза. Әсез – мең дә беренче сатып алучы. Шуңа күрә менә мондый чарада катнашу хокукы бирелә. Менә шушы арба белән кибеткә керәсез дә нәрсә кирәк, шуны алып чыгасыз. Әгәр өч минут эчендә өлгерәсез икән, барысы да бушлай. Өлгермәсәгез – ярты бәясенә.

Тегe кеше сөенеп кибеткә кереп китә, ә бу шаян төркем шундук эреп юкка чыга. Акциядә катнашучыны үзегез дә күз алдына китерә аласыз инде. Ул йөгерә-йөгерә арбасын тутыра һәм кибет хезмәткәрләренең аптыраулы карашына, кисәтүенә дә игътибар итмичә, касса янынннан узып, урамга атылып чыга. Ә анда беркем дә юк...

Без дә сезгә шундыйрак бер шаяру тәкъдим итәбез. Ә аңа кадәр – кечкенә мәзәк. Бәлки, күпләрегез аны беләдер дә. Шулай да искә төшереп узыйк әле...

– Мин инде беренче сыйныфта гына укырлык дәрәҗәдә түгел, апа, – ди малай укытучыга. – Минем апам өченчедә укый, ә мин аннан күпкә акыллырак, шуңа мине дә өченче сыйныфка күчерсәгез иде.

– Яхшы, – ди укытучы апа. – Әйдә директор янына барабыз. Әгәр ул риза була икән, өченчегә күчәрсең.

Укытучы апа башта директор янына кереп хәлне аңлатып бирә.

– Яхшы, – ди директор. – Керсен. Мин берничә сорау бирермен, дөрес җавап кайтарса, күчерербез.

Шуннан малайны чакырып алалар. Үзләренчә кечкенә имтихан оештыралар.

– Өчне өчкә тапкырлагач, ничә була?

– Тугыз.

– Ә алтыны алтыга тапкырласаң?

– Утыз алты.

Шул рәвешле бер сәгать буена директор сораулар яудыра, ә малай күз дә йоммыйча җавап бирә һәм бер тапкыр да хаталанмый. Ниһаять, директор аның теләген үтәргә риза була. Тик укытучы апа өчен бу котелмәгән хәл. Мондый белемле баланы үз сыйныфыннан ерак җибәрәсе килми. Шуңа күрә соңгы чарага ябыша.

– Миңа да берничә сорау бирергә мөмкинме? – ди ул, күзләрендәге хәйләкәрлекне яшерергә тырышып. Әлбәттә, директор да, малай да каршы килми. Һәм укытучы башлый:

– Сыерныкы дүртәү, ә минеке икәү генә. Ул нәрсә була?

– Аяклар, апа.

– Синең чалбарыңда бар, ә минекендә юк?

Директор, дулкынланып, күзлеген сөртергә тотына. Ә малай тыныч кына җавап бирә:

– Кесәләр.

– Житте, житте! – дип бүлдерә директор чираттагы соравын бирергә җыенган укытучыны. – Бу малайны алтынчы сыйныфка күчерәбез. Ул мин ялгышкан урында да дөрес җавап бирде.

Бу мәзәкне искә төшерү бер дә юктан гына түгел. Игътибарлырак булыгыз. Әзер җавапларга карамыйча гына җавап бирегез. Киттек.

Галәмдәге ерак йолдызларны күрергә ярдәм итүче җайланма ничек атала?

Җавабыгыз әзерме? Дөрес, әлбәттә. Ул «телескоп» дип атала.

Икенче сорау. Бик кечкенә кисәкчәләрне күрергә ярдәм итүче нәрсә?

Тагын сез хаклы инде. Әлбәттә, микроскоп.

Монысы аз гына катлаулырак. Игътибарлырак булыгыз. Су астында йөргән чакта су өстен күзәтергә ярдәм итүче җайланма ничек дип атала?

Әлбәттә, шулай. Перископ.

Сезнең белемгә һәм тапкырлыкка берничек тә шикләнерлек түгел. Төрмышның һәртөрле сорауларына җавап таба-таба чарланып беткәнсез инде. Шулай да дүртенче сорауны бирми булмый. Монысы тагы да катлаулырак. Стена аша карарга булышлык итүче җайланма нәрсә була?

Яхшырак уйлагыз. Ашыкмагыз. Бирелгәсезмени инде? Ә җавап болай гади генә иде үзе. Тәрәзә дип атала ул.

Тормыш куйган сорауларга җавап биргәндә дә берау шаянрак булыгыз. Дөреслек бер генә төрле түгел ул, ә шаяруга төрелгән дөреслек һәрвакыт дөрес.




**11 март санында чыккан сканвордның җаваплары**
**Горизонталь буенча:** Загреб, секанс, Күн, спа, беләү, тик, ел, Әнәс, битәр, кәй, Бор, фәләк, дүдәк, юача, зая, гандбол, коала, капкын.
**Вертикаль буенча:** итәк, дог, Алек, инәлү, Күзкәй, Руан, фәрд, бәк, баскетбол, Токай, ирәю, лоп, Сәет, каз, акт, пүләп, чаклы, бая, Ани.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

КОМБИКОРМА, ЗЕРНО
Комбикорм для БРОЙЛЕРА ФИНИШ (от 26дней)
25 кг – 1070 р/мешок
Комбикорм для БРОЙЛЕРА СТАРТ (0-25 дней)
25 кг – 1350 р/мешок
Полный ассортимент: agroline1.ru
Казань, Техническая, 15.
тел.: +792-704-99-706
Реклама

КАРНИКА һәм КАРПАТКА
токымлы бал кортлары семьясын сатам.
4 рамкалы, 2-3 кәрәзе – личинкалы,
1 кәрәзе – бал икмәге белән.
+7 96 55 99 88 67,
+7 96 25 61 60 93
Пчелопакет Карника и Карпатка комплектация по 4 рамки 2-3 расплодом +1 медаперговая
Реклама



**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
**Индекс П2435**
**Тираж – 17132 данә**
**Газетага сертификат бирелде**
Заказ 237

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+